

ГОРУРЛАН, ӘНИ!
Солдат аналары улларының соңгы сүзләрен искә төшерде
> 3

80 СЕКУНД
Ананы һәм баланы коткару өчен, шушы кадәр вакыт бирелгән
> 4

ИЛЬЯС МИНҺАҖЕВ:
«Бу адымга барганчы, күп тапкырлар сөйләшеп карадык, безне ишетүче булмады»
> 6

ШӘТКЕ ТӘРБИЯСЕ
«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турында махсус проекты
> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 174–175 (29141–29142) | Сишәмбе | 28 ноябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ИЛ ТЕРӘГЕ

ВЛАДИМИР ПУТИН 2024 ЕЛНЫ ГАИЛӘ ЕЛЫ ДИП ИГЪЛАН ИТТЕ

Бу елдан нәрсә өмет итәргә? Балаларга һәм ата-аналарга игътибар җитәрлекме? Без әнә шул хакта сораштык.

Балтач районыннан Лилия һәм Рөстәм Заһидуллиннар 2008 елда гаилә кора. Өч бала үстерәләр. Төп нигездә әти-әни белән бергә яшиләр. Сүз уңаеннан, Заһидуллиннар моннан берничә ел элек «Ел гаиләсе» бөтенроссия конкурсында «Авыл гаиләсе» номинациясендә җиңү дә яулады.

– Ил җитәкчеләре бик мөһим һәм мәгънәле юнәлешне күтәреп алган, – ди гаилә учагын саклаучы Лилия ханым. – Елның темасына карап кына гомер итмәсәк тә, күңел гел яхшы хәбәр, бәрәкәтле ел көтә инде ул. Шулай булыр дип ышанабыз да.

Лилия Заһидуллина фикеренчә, Гаилә елында финанс һәм торак мәсьәләләренә күбрәк игътибар бирелергә тиеш.

– Күбрәк гаиләләр катнаша алырдай торак программаларын булдырсак, бюджет өлкәсендә хезмәт итүчеләрнең хезмәт хакларын шәһәрдәгеләргә караганда югарырак итсәк, нигез, авыл, гаилә бердәмлеген саклауга зур этәргеч булыр иде бу, – ди ул. – Ирем – яшьләр сәясәте буенча җаваплы җитәкче, шуңа да гаилә темасына күп фикерләшәбез. Яшьләр арасында үз ярларын табу, парлыларны саклау ил күләмендәге актуаль мәсьәлә булып кала. Тәрбияле гаиләдән тәрбияле буын чыгачак.

Казаннан Марта Галицкая – дүрт бала анасы. Киләсе елдан ул ни өмет итә икән?

– Безнең Россиядә дөрес гаилә кыйммәтләре алга сөрелә. Бу куандыра. 2024 ел күпбалалы гаиләләргә куанычлы яңалыклар гына алып килер дип өметләнәбез, – ди ул. – Яңа социаль түләүләр, 3 һәм аннан да күбрәк балалары булганнарга ярдәм чаралары, югары уку йортына кергәндә ташламалар көтәбез. Өченче бала өчен бирелә торган җир участогын көтү дә бик озак. Җир кишәрлекләре дә юлсыз, утсыз, дигәндәй. Гаилә елында моңа да игътибар итсеннәр иде инде. Үз гаиләм мисалында тагын шуны әйтә алам: без алтау һәм барыбыз да сыярлык машина сатып алу мөмкинлеге юк. Дәүләт ярдәменнән башка хәл итеп булмый моны.

Сан



✓Росстат мәгълүматлары буенча, былтыр Россиядә 1053756 пар гаилә корган, 682850се аерылышкан. 2021 ел белән чагыштырганда, гаилә коручылар 12,4 процентка арткан.

✓Татарстанда күпбалалы гаиләләр саны:

2012 ел >> **24,8 мең**

2022 ел >> **40,5 мең**

Илдар Мөхәммәтҗанов

Илдә Гаилә елы беренче тапкыр 2008 елда игълан ителгән иде. 2024 ел да гаиләне яклау һәм традицион кыйммәтләрне саклау юнәлешенә багышланачак.

Татарстанның атказанган артисты Лилия Муллагалиева – бер кыз, өч малай әнисе. Гаилә стажы – 24 елдан артык.

– 2024 елны Гаилә елы итеп игълан иткәч, бик сөендек. Хәзерге көндә ил күләмендәге һәм, гомумән, Җир йөзендәге җитди мәсьәлә булып гаиләләрнең тотрыклылыгы тора. Минемчә, хәзерге көндә психологлар, галимнәр, күп еллар бергә яшәгән гаиләләр җыелышып, дәреслек әзерләргә тиеш. Мәктәптә үк гаилә этикасы, гаилә кыйммәтләре, балаларны гаилә тормышына әзерләүгә бәйле фән кирәк. Әйтик, 8–11 нче сыйныфлардан башларга. Бала-чаганың башы мәктәптәге биремнәр белән каткан инде ул. Гаилә эчендә дә мондый темаларга сөйләшү аз бит. Укып бетергәч тә, яшьләр дөнья көтү, акча эшләү мәшәкатьләренә чума. Гаилә кору мәсьәләсе шулай итеп артка күчә. Милләтнең, яшәешнең, дөньяның алга баруы гаиләдән һәм аларның ныклыгыннан тора. Кешеләргә әнә шуны аңлатырга кирәк. Яшь гаиләләргә финанс ягыннан ярдәм итсәләр, бик яхшы. Бәлки, рәсми рәвештә танышу, кавышу өчен сайтлар кирәктер. Кеше хәзер социаль челтәрләрдә утыра, – диде Лилия Муллагалиева.

> **Россия Президенты Владимир ПУТИН:**
> «Аналарга һәм балаларга ярдәм итү, демографик хәлне яхшырту, Россия гаиләләренең тормыш сыйфатын тәэмин итү мәсьәләләре өстенлекле юнәлешләр арасында тора. Гаилә ул – нигезләрнең нигезе. Нәкъ менә өйдәге гаилә шартларында кешенең шәхесе һәм дөньяга карашы, аның рухи-әхлакый сәяси идеаллары һәм кыйммәтләре формалаша».

Ахыры 2 нче биттә >

Көтәсе күп калмады

Мәскәү белән Казанны тоташтырачак түләүле юлның Татарстан аша узучы өлеше (сигезенче этап) 95 процентка әзер. Бу хакта Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин әйткән.

Трассаның иң зур ясалма корылмасы – Идел елгасы аша күпергә асфальт инде тулысынча түшәлгән, яктырткычлар, барьерлар урнаштырыла. 3,3 чакрымнан артыграк озынлыктагы күпер Лаеш белән Югары Ослан районнарын тоташтыра. Металл конструкциясенең гомуми авырлыгы 45 мең тонна тәшкил итә.

Юлның сигезенче этабында тәүлек әйләнәсе эш гөрли. «Автодор» рәисе Вячеслав Петушенко сүзләренә караганда, биредә 4,1 мең кеше һәм 916 берәмлек техника эшкә җигелгән. Хәзерге вакытта тавыштан саклау экраннары, юл хәрәкәтен автомат идарә итү системалары кысалары урнаштырыла. Машина йөртүчеләр өчен ял мәйданчыклары, юл сервислары да ачылышка әзер булачак.

Өченче һәм беренче!

Россия төбәкләренең инвестицияләр җәлеп итү мөмкинлекләре рейтингында Татарстан янә өченче урынга чыккан. Илкүләм рейтинг агентлыгы (НРА) уздырган тикшеренү нәтиҗәләре буенча, республика Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан гына калышкан. Ямал-Ненец автономияле округы, Мәскәү өлкәсе – дүртенче һәм бишенче урыннарда. Әйтергә кирәк, әлеге биш төбәк узган елда да шундый ук урыннар алган.

Шул ук вакытта без бу җәһәттән Идел буе федераль округы төбәкләре арасында беренчелеккә чыкканбыз. Түбән Новгород, Самара, Оренбург өлкәләре һәм Пермь крае да беренче бишлеккә кергән.

Әйбәт төзиләр

Татарстанда торакны файдалануга тапшыру планы 97,5 процентка үтәлгән. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин әйтүенчә, барлыгы 3,2 миллион кв. м торак мәйданы төзеп тапшырылган.

Төзелгән барлык йортларның 12 миллион кв. м мәйданы (151 күпфатирлы йорт) – коммерция торагы. Бу җәһәттән план 85 процентка үтәлгән. Социаль ипотека программасы буенча 61 йорт (147 мең кв. м мәйданда) төзелгән. Еллык план 91 процентка үтәлгән.

Ә инде шәхси йорт төзү планы арттырып та үтәлгән. Әзер йортларның гомуми мәйданы 1 миллион 668 мең кв. м тәшкил итә.

Кырыс ноябрь

Бу атнада Татарстанда янә һава торышының бозылуы көтелә. Юеш кар, буран, урыны белән бозлы яңгыр булачак, томан төшәчәк. Юлларда – көчле бозлавык.

Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, чәршәмбе – 29 ноябрьдә кар явачак, аз гына буранлап торачак. Көньяк-көнбатыштан секундына 5–10 метр, төнлә урыны белән 12 метр тизлектә җил. Көндез термометрның терекөмеш баганасы –3…–8 градус, төнлә –5…–10 градуска кадәр төшәчәк. Юлларда – урыны белән бик көчле бозлавык. Пәнҗешәмбе – 30 ноябрьдә көнбатыш районнарда көн азагында гына явым-төшем көтелә. Көндез һава температурасы –4…–9 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә –11…–16 градуска кадәр суыта.

Синоптикларның башлангыч мәгълүматларына караганда, җомга һәм шимбә – 1, 2 декабрьдә кар-буран, көчле җил булыр дип фаразлана. Көндез һава температурасы –1…–6 градус тәшкил итәчәк. Юлларда – бозлавык, урыны белән кар «ботка»сы.

Борчыган мәсьәлә

Утсыз төтен

Җиде елга кадәр иректән мәхрүм итәргә. Депутатлар вейпларда кулланыла торган сыекчаны илгә законсыз керткән өчен әнә шундый җәза тәкъдим итә. Федерация Советының икътисадый сәясәт буенча комитет вәкилләре законга шундый төзәтмә әзерләгән.

Соңгы арада вейпларга бәйле мондый тәкъдимнәр аеруча еш яңгырый. Әле күптән түгел генә депутатлар электрон тәмәке сату таләпләрен көчәйтергә, аларга тәм бирүче кушылмаларны тыярга тәкъдим иткән иде. Баласы вейп тарткан ата-анага штраф салырга кирәк, диючеләр дә булды. Ничек кенә булмасын, вейпларга каршы көрәш туктаусыз бара, нәтиҗәсе генә әллә ни сөендерми. Электрон көпшә көйрәтү баласына да, анасына да гадәти хәлгә әверелеп бара. Бүген хәтта чеп-чи татар авылларында да тамыр җәяргә өлгерде ул.

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, Җир шарында һәр ун секунд саен (!) бер тәмәкече үлә. Вейп аркасында якын киләчәктә бу коточкыч саннар тагын да артырга мөмкин, дип фаразлый алар. Анысының зыяны әле дә булса ахыргача өйрәнелеп бетмәгән. Күптән түгел Корея галимнәре вейпның бер капсуласында бер кап тәмәкедәге кадәр никотин барлыгын ачыклаган. Вейплар үпкә авырулары килеп чыгу ихтималын – 50 процентка, инсульт куркынычын 71 процентка арттыра, дип чаң суга белгечләр. Хайваннарда уздырылган тәҗрибәләр вейпларның эчәклеккә дә зыян салуын күрсәткән.

Татарстан Иҗтимагый палатасы әгъзасы, «Татарстанның күпбалалы гаиләләре» төбәкара иҗтимагый оешмасы рәисе Артем Кузнецов фикеренчә, вейплардан ниндидер чикләүләр ярдәмендә генә котылып булмый. Вейплар сатудан бөтенләй алынган очракта гына нәтиҗәсе булырга мөмкин, дип саный ул.

– Күз алдында торганда, вейп тартасы килгән үсмер аны барыбер кулга төшерәчәк. Бигрәк тә янәшәдә аны көйрәткән кешеләр булганда, бу әллә ни зур авырлык тудырмаячак. Әгәр син балаңның вейп тартмавын телисең икән, син, иң беренче чиратта, моны үзең эшләмәскә тиеш. Ә бүген күреп торабыз: олысында да, кечесендә дә шул әйбер, – ди ул.

Әлмәт үзәк район хастаханәсенең табиб-пульмонологы Рөстәм Насретдинов та шул фикердә. Вейп кулланучылар сафының «яшәрә» баруына аеруча борчыла ул. Аңа хәтта вейп тарту аркасында үпкәләре зарарланган сигез яшьлек (!) малайга ярдәм итәргә туры килгән.

– Хроник үпкә авырулары булган, бронхиаль астмадан интеккән кешеләр өчен вейп, электрон тәмәке тарту аеруча куркыныч. Аларны тартканда кан тамырлары, югары сулыш юллары кысыла. Шул мизгелдә янында ярдәм итәр кешесе булмаса, кеше үлеп тә китәргә мөмкин, – ди табиб. – Тәмәкенең үпкә, бронхларга бәйле авырулар, яман шеш китереп чыгаруы күптән фәнни расланган. Вейпларның составында ниләр барлыгы да, аның организмга салган зыяны да тиешенчә өйрәнелеп бетмәгән. Шуңа күрә вейп сатуга таләпләрне һичшиксез көчәйтергә кирәк.

Сүзгә-сүз

Инна СВЯТЕНКО, РФ Федерация Советы вице-спикеры:

Ил киносы «дөрес гаилә»ләрне гәүдәләндерергә тиеш. Югыйсә күпчелегенең сюжеты авылдан килгән кызның, бай гаиләне җимереп, бәхеткә ирешүенә багышланган. Ә балалар турында уйлаучы да юк. Рекламада да бәхетле гаилә әти, әни һәм бер баладан гына тора. Күпбалалы гаиләләрне күрсәтик.

«Парламентская газета» басмасыннан

РОССИЯДӘ ЯШӘҮЧЕЛӘРНЕҢ ТОРМЫШ КЫЙММӘТЛӘРЕ

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россиядә яшәүчеләрнең төп тормыш кыйммәтләре турында сорашкан.

1. Ныклы гаилә
2. Патриотизм
3. Ил белән горурлану
4. Тарихи хәтер
5. Дуслык
6. Хокук һәм ирек

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ТЫНЫЧЛЫК КҮПМЕГӘ БАРЫР?

Үткән атнада дөнья сәясәтенең төп вакыйгасы Израиль белән ХАМАС арасындагы утны дүрт көнгә туктатып тору турындагы килешү булды. Килешү кысаларында тоткыннарны алмаша башладылар.

ХАМАС – 50 тоткынны, Израиль төрмәләрдән 150 фәләстыйнлыны чыгарырга тиеш. Моннан тыш ХАМАС Таиланд гражданнарын килешүдән тыш азат итүне үз өстенә алды. Беренче тоткыннар азат ителде инде. Израиль табиблары Газзәдән кайтучы гражданнарның сәламәтлеге яхшы булуын әйтә. Америка телевидениесенә ышансаң, килешү тагын да озайтылырга мөмкин. Мисыр һәм Катар арадашчылыгы ярдәмендә авыр һәм катлаулы процесс дәвам итәргә тиеш. Фәләстыйнлылар, Израиль килешүне даими боза, диләр.

Сүз гадәти төбәк конфликты турында гына бармый. Көнбатыш белән ислам дөньясының үзара чәкәләшүенә китерү куркынычы зур булган каршылык үсә. Мөселман илләре җитәкчеләре Америка куйган таләпләрне тегәл үтәргә тырыша тырышуын, әмма урамнар тыныч түгел. Дәвамлы конфликтның зур фетнәгә китерү хәвефе бар. Көнбатышның үзендә дә урам протестлары бара. Газзәдәге сугеш көнбатышлыларның ислам белән кызыксынуын арттырды. Зур кризис адымнарын тизләткәндә, сәясәттә урамнар йогынтысы зур булуын бар дөньяда аңлыйлар.

Көнбатышта икътисадый хәл мактанырлык түгел. Бер Америка гына әлегә үзен рецессия хәвефеннән имин тота. Германиядә җитештерүнең кимүе бюджет кризисына китерде. Илнең Финанс министрлыгы дәүләт чыгымнарын тундырырга мәҗбүр, чөнки 2024 ел бюджетында 60 миллиард евролык «ертык» барлыкка килгән. Европада нефть химиясе сәнәгатенең үлем хәлендә булуы турында хәбәрләр килә. Заводлар чимал эшкәртүне 1975 елгы дәрәҗәгә кадәр киметкән. Кризис нәтиҗәсендә хакимияткә үтә уң радикаллар килү куркынычы арта. Нидерландта сайлауда Геерт Вилдерсның үтә уң партиясе җиңде. Вилдерс – исламга дошманлыгы, расачыл карашлары белән танылган кеше. Ул ил хөкүмәтен җитәкләргә тели һәм Нидерландны Евросоюздан чыгарырга вәгъдә итә.

Ислам дөньясында да Көнбатыш белән конфликт ихтималын яхшы аңлыйлар. Европа һәм Америкадан технологик бәйлелектән котылуның зур адымнары ясала. Төркиянең сәнәгать һәм технологияләр министры Фатих Качыр: «Бүген Төркия катлаулы технологияләр җитештерергә сәләтле илгә әверелде», – дип белдерде. Төрекләр, чынлап та, инновацияләр өлкәсендә ыргылыш ясый, әмма кайбер тармакларда Көнбатышны артта калдыру кузәтелсә дә, гомумән алганда, бәйлелек барыбер зур әле. Икенчедән, хәрби өлкәгә һәм технологияләргә бюджеттан зур инвестицияләр ясау финанс тотрыксызлыгына китерде. Үткән атнада төрек банкы төп ставканы 40 процентка җиткерде.

Россиядә

САЛЫМНАР ҖЫЮ АРТА, ӘММА...

Россия 2023 елны зур тетрәнүләрсез генә төгәлләр кебек. Финанс күрсәткечләре начар түгел, әүке тулай продукт та Украина белән конфликт алдындагы елны узып китте. Ләкин хәрби сәнәгать продукциясен җитештерү арта, гражданлык продукциясе кими. Хәрби сәнәгатькә чимал җитештерүче тармаклар да үсештә. Болар халыкның матди хәлен яхшыртмый шул.

Инфляция көчәя һәм аны авызлыклап булырга охшамаган. Моны Үзәк банк таный. Төп ставка 16 процентка җитәргә мөмкин дигән фаразлар яңгырый. Салым федераль хезмәте быел салымнарның үткән ел белән чагыштырганда 9 процентка күбрәк җыелуын хәбәр итте. Әмма салымнар, бәяләр югарырак булган саен, күбрәк җыела. Бу – аксиома, моның нәрсәсенә сөенәсең? Житмәсә, олигарх Олег Дерипаска 2024 ел бюджетына начар нәтиҗәләр юрый: 10–12 триллион сум акча җыелмый калачак, ди. Бу – аның шәхси фикере генә, билгеле. Тик Россия икътисадында проблемалар йомгагы үсә, монысы – факт.

Федераль бюджет үзен яхшы хис итсә дә, төбәк бюджетларының бурычы кискен темплар белән арта. Гомуми әҗәт 3,153 триллион сумга җиткән инде. Бу 2022 ел ноябренә караганда 421 миллиард сумга күбрәк. Иң зур бурыч Мәскәү өлкәсенеке – 320 миллиард сум. Мәскәү 264 миллиард сумлык әҗәт туплаган, Түбән Новгород өлкәсе – 138 миллиард, Татарстан 116 миллиард сум җыйган. Төбәк хөкүмәтләре федераль үзәк белән бергәләп бу проблеманы чишәрләр, билгеле, әмма бурычларны каплау өчен безнең кесәгә да керми калмаслар. Инфляция булышыр. Гыйнварда ук сөт продукциясенә һәм сырларга бәяләр 10 процентка күтәрелер дигән хәбәрләр бар. Сыер ите җитештерүчеләрнең Милли союзы генераль директоры Роман Костюк ит бәясенең бәйрәмнәрдә кимендә 7–10 процентка кыйммәтләнәчәген фаразлый.

Быелның октябренә аяк киемнәре бәясе үткән елның шул чоры белән чагыштырганда – 25 процентка, өс киемнәренеке 21 процентка үскән. Санкцияләргә кадәрге 2021 ел октябре белән чагыштырганда аяк киемнәре – 51 процент, өс киемнәре 41 процент бәя өстәгән.

Көнбатыш безгә аяк чалу омтылышларын туктатмый. АКШ Россия нефтен «түбә бәя»дән югарырак бәягә ташучы танкерларны эзәрлекли башлады. Нәтиҗәдә ноябрьдә диңгез аша нефть ташу кискен кимеде.

АКЧА КЕМ КУЛЫНДА?

Эшлекле форум

113 миллиард сум. Татарстанда дәүләт һәм бизнесның уртак хезмәттәшлеге әнә шул күләмдә бәяләнә. Барлыгы 126 проект бар. Аның кысасында яңа уку елы башында республикада өч мәктәп кулланышка тапшырылган инде. Ел азагына кадәр тагын ике спорт корылмасы төзелеп бетәргә тиеш. Шәхси кулдагы акчаны ничек җәлеп итәргә? Казанда узучы җыенда шул хакта фикер алышалар.

– Дәүләти-шәхси хезмәттәшлек (ГЧП) – ил икътисадының мөһим өлеше, – диде Дәүләти-шәхси хезмәттәшлек буенча VI төбәкара форумның пленар утырышында Татарстан Премьер-министрының беренче урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин. – Бигрәк тә бүгенге вазгыятьтә бизнес дәүләт ярдәменә мохтаҗ. Ә дәүләткә исә инфраструктураны яңартуны дәвам иттерергә кирәк. Уртак хезмәттәшлек нәтиҗәсендә бизнес тотрыклы керем алса, гади халык сыйфатлы хезмәтләрдән файдалану мөмкинлегенә ия була. Татарстанда бизнеска шартлар булдыру юнәлешендә шактый эш башкарыла. Шул исәптән дәүләти-шәхси хезмәттәшлек өлкәсендә дә. Бүген Татарстанда моңа бәйле 126 проект бар. Аларның гомуми бәясе 113 миллиард сум.

Әлеге мәсьәлә бик катлаулы. Моны форумның пленар утырышы барышында кат-кат искәрттеләр. Шуңа күрә аны шулай бер мәйданда җыелып фикер алышу, тәҗрибә уртаклашу мөһим. Гадәттә мондый чаралар башта аерым юнәлешләр буенча сөйләшү, ә аннары йомгаклау рәвешендә пленар утырыш үткәрү рәвешендә оештырылса, бу юлы киредән башладылар. Казанда узган форумга илнең 35läп төбәгеннән катнашучылар килгән. Пленар утырышта алар арасында сораштыру да үткәрделәр. «Җыенга ни өчен килдегез?» дигән сорауга залда утыручыларның 80 проценттан да күбрәге: «Яңа белем тупларга», – дип җавап бирде.

Мондый белем Татарстанда бар. Моны илкүләм саннар да дәлилли.

ДӘҮЛӘТИ-ШӘХСИ ХЕЗМӘТТӘШЛЕКНЕ ҮСТЕРҮ БУЕНЧА ИЛКҮЛӘМ РЕЙТИНГ

1 >>	Түбән Новгород өлкәсе
2 >>	Хабаровск крае
3 >>	Омск өлкәсе
4 >>	ТАТАРСТАН
5 >>	Пермь крае

– Дәүләти-шәхси хезмәттәшлекне үстерү буенча илкүләм рейтингта Татарстан – дүртенче урында, – диде республиканың Инвестиция үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина. – Әле берничә ел элек кенә исемлекнең 67 нче баскычында булсак, бүген беренче бишлеккә керәбез. Дөрес, беренче өчлеккә түгел әле. Әмма моңа анлатма бар. Татарстан – донор төбәк. Республикада күп социаль проектлар бюджет хисабына тормышка ашырыла. Ә аларга шәхси акчаны җәлеп итү кыйммәтрәккә төшәргә мөмкин. Сүз инвесторлар гына түгел, ә банклар турында да бара. Моңа да карамастан, без әлеге юнәлештә тырышып эшлибез. Бу елның 1 сентябрендә республикада дәүләти-шәхси хезмәттәшлек кысасында төзелгән өч мәктәп ачылды. Инвестицияләрнең гомуми күләме 7,8 миллиард тәшкил итте. Әлеге уку йортлары Казанда, Чаллыда һәм Арча районында урнашкан. Федераль субсидияләр җәлеп итү бәрабәренә Әлмәт һәм Чаллы шәһәрләрендә ике футбол манежы төзелә. Казанда һәм Яшел Үзәндә тагын ике спорт корылмасын сафка бастыру нияте бар.

Дәүләт һәм шәхси бизнес хезмәттәшлеге турында сөйләгәндә, республикада тормышка ашырылучы зур юл төзелешен дә искә алырга кирәк. Билгеле булганча, Шәле – Баулы автомобиль юлын концессион килешү (ГЧПның бер төре. – **Ред.**) нигезендә салалар. Әлеге трасса М7 һәм М5 федераль юлларын тоташтырачак. Хәзерге вакытта аның бер өлеше булган Алексеевск – Әлмәт юлында эш тәмамланып килә.

Республикада бу өлкәдә укыту да оештырылган. Быелның август – октябрь айларында Татарстанда йөздән артык дәүләт хезмәткәре дәүләти-шәхси хезмәттәшлек буенча укыган. Имтихан да тотачаклар. Тик парта арасында түгел, ә форумда.

– Укуда катнашучылар республикада яшәүчеләрнең тормыш шартларын яхшыртуга бәйле проектлар әзерләде. Форумда аңа шуларны тәкъдим итәчәкләр. Табадан төшкән яңа проектлар инвесторларда кызыксыну уятыр, дип өметләнәбез, – диде Татарстанның Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ИЛ ТЕРӘГЕ

Башы. Ахыры 1 нче биттә >

Әлбәттә, Гаилә елы уңаеннан чаралар күп булыр. Концертлар да куярлар, гаиләләр турында матур сүзләр дә ишетелер, урнәкләре сәхнә тотар. Әмма күп нәрсә сүздә генә калмасын иде. «Общественное мнение – Татарстан» фонды директоры урынбасары Елена Бондаренко шундый фикердә.

– Гаиләсез илнең киләчәге юк. Мисал өчен, Европа илләренең рәсми затларына күз салыйк. Күпчелегенең балалары юк. Үзләреннән соң нинди ил калыр – аларга барыбер. Вакытлыча яшәүчеләр психологиясе бу. Ягъни бүген һәм хәзергесе мөһим, – диде ул «ВТ» хәбәрчесенә. – Россиядә гаилә мәсьәләсенә аерым игътибар бирелә икән, димәк, бу – киләчәктә балаларга кала торган ил турында кайгырту дигән сүз. Шунысы да мөһим: идея, лозунглар белән генә чикләнмәскә иде.

Елена Бондаренко яңа гына гаилә коручылар, яшьләр өчен баш бәласе булган кайбер мәсьәләләргә дә тукталды.

– Сер түгел, торак алу мәсьәләсе яшьләр өчен бик кискен тора. Әлбәттә, кайбер сәясәтчеләр бушлай йорт, фатир бирик дип тә әйтеп карады. Әмма хәзерге икътисадый вазгыятьтә моның мөмкин түгел икәнлеген барыбыз да аңлый, – диде белгеч. – Мәсьәләне хәл итүнең башка юлларын уйларга кирәк. Әйтик, фатирның ипотекага түгел, кичектереп түләү шарты белән бирергә. Процентларсыз, өстәмәләрсез. Тагын бер тәкъдим: бала туган саен, билгеле бер суммада торак түләвен киметү. Әйтик, беренче бала тугач – 500 мең, икенчесе тугач – 500 мең сум. Бөби алып кайтырга курыкмаслар иде. Чөнки кредит тозагында калмаячакларын алдан ук беләләр. Бу чын мәгънәсендә стимул булыр иде.

Елена Бондаренко, рухи-әхлакый, мәдәни яктан да ярдәм кирәк, ди. Шул ук «Пушкин картасы» кебек проектларның акчасын арттыру, мәдәни чараларга, түгәрәк, секцияләргә булган түләүне киметү.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Экология

Үзебездән тора

Казанда Россиянең төрле төбәкләреннән килгән белгечләр катнашында «Сулыкларны саклау һәм савыктыру» дигән темага семинар узды. Анда Татарстандагы бу юнәлештә барган эшләрне мактап телгә алдылар.

Россиянең табигать һәм экология министры урынбасары Павел Барышев бездәге тәҗрибәне башка төбәкләргә үрнәк итеп куйды. Әлеге семинарның Татарстанда узуы тикмәгә түгел. Исегезгә төшерәбез: күптән түгел безгә Россия вице-премьеры Виктория Абрамченко килгән иде. Ул күп кенә экология проектларының үтәлеше белән танышты. Шуннан соң башка төбәкләргә дә Татарстан тәҗрибәсен өйрәнергә кушкан.

– «Иделне савыктыру» федераль проекты 2019 елда башланды. Ул 2024 елда тәмамлана. Аннан соң Иделне кайгыртучы «Сулыкларны саклау» проекты барлыкка киләчәк, – ди Павел Барышев. – «Идел» елгасы – 60 миллион кешенең «өе». Елга янәшәсендә күп кенә сәнәгать, авыл хуҗалыгы оешмалары урнашкан. Уртача алганда, алардан чыккан зарарлы матдәләр Иделгә килә торган зыянны 5 тапкыр арттыра. Әнә шуңа да без сулыкка зыян салуны киметергә тиеш. Монда безгә Татарстан тәҗрибәсе ярдәм итәчәк дип уйлыйм.

Татарстанда ниләр эшләнә соң? Бу сорауга җавапны Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков бирде:

– Иделне савыктыруда биологик чистарту корылмалары ярдәм итә. Аларны яңарту Татарстан башкаласында яшәүче 1,3 миллион кешенең тормыш шартын яхшыртты. Чистарту корылмаларында тотып калынган калдыкларны киптерел барабы. Шул рәвешле ләм басулары башта киптерелә, аннан юкка чыгарыла.

Александр Шадриков ләм басуларында эш башлаганчы фән белгечләре белән киңәшләшүен, бу өлкәдә 36 дөньяви технология кулланулары әйтте.

– Быел Татарстанда сулыкларда тик ятучы нефть торбаларын чыгару эшләре тәмамланды. 23,7 чакрымга сузылган торбаларны җир өстенә чыгардык. Моны тормышка ашыру өчен 930,5 миллион сум акча тотылды. Нинди генә эшкә тотынма, республика җитәкчелеге, бизнес вәкилләре, фән, җәмгать эшлеклеләре белән бергәләп киңәшләшергә кирәк. Бары тик шул вакытта гына уңышка ирешеп була, – ди Александр Шадриков.

Төбәкләрдән җыелган белгечләрне Казан янәшәсендәге ләм басуларына да алып бардылар. Бирелә эшләр 2021 елдан бирле башкарыла. Ул 2024 елда тәмамланыр дип көтелә. Әлегә барлык эшләрнең 61 проценты үтәлгән.

Эш барышы белән «Ядран-строй» оешмасы генераль директоры Марат Хәйруллин таныштырды.

– Биргә 40–50 ел буе барлык биологик чистарту корылмаларында ләм җыелып яткан. Хәзер аларның һәркайсы чистартыла, киптерелә һәм ваклана, – ди ул. – 50 ел эчендә биргә 4 миллион кубометр ләм чыгарылган.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

tatar-inform.ru

ТҮБӘ БАР

«КЫЗЫЛ ЮЛ» ХУҖАЛЫГЫНДА БЕЛГЕЧЛӘРГӘ ФАТИР ТӨЗЕП БИРӘЛӘР

Яшәеш

Балтач районының «Кызыл юл» хуҗалыгы бу көннәрдә җиденче фатирын түбә астына керткән. Элекке социализм чорындагы колхозлар системасында (гомумән, ил күләмендә) бу метод бик популяр һәм гадәти хәл иде. Шуңа күрә кадрлар проблемасын да чиштеләр, демографиягә, авыллар язмышына кагылышлы сораулар тумады.

Шәһәрдә яшәүчеләрнең дә үз куышларын булдыру гарантиясе зур иде. Эш урыннарыннан бирелгән тулай торактан, коммуналь фатирлардан бүлмәләр бик күпләргә заманча фатирларга юл башы булды. Хәзер инде болар барысы да «теге» заманнын бер ядкаре генә булып калды.

Моннан берничә ел элек Балтач районындагы хуҗалыклар, кадрлар проблемасын хәл итү өчен, яшьләрне авылда калырга кызыктырып булмасмы дип, фатирлар төзеп караган иде. Кайберсе бераничә ел буш торды, хуҗалыклар, үзләренә зыянга булса да, әлеге йортларны кыш буе ягып, җылытып чыкты – аларга тиз генә кызыксынучы табылмады. «Кызыл юл» хуҗалыгында да, мәрхүм авылдашым, күрше егете Ирек зоотехник, ферма мөдире булып эшли башлагач, аңа дип атап, ике катлы искитмәле йорт төзегәннәр иде. Тик ул чакта Иреккә һәм гаиләсен әти-әнисе төп йорттан җибәрмәде. Ул егерме биш чакрымга якын араны йөреп эшләде. Иреккә дип төзелгән йорт та берничә ел буш торды. Кирәксенүче булмагач, билгеле, фатирлар төзелеше әллә ни җәелеп китә алмаган иде. Соңгы елларда үзгәрешләр булган, димәк. Тикмәгә генә җиденче фатирны төземиләр бит инде. Хәл белешеп, хуҗалык җитәкчесе Фердинанд Хәйруллинга шалтыраттым.

Гөлзифа Нәҗипова

Йортны үзеңнеке итәр өчен, ун ел эшләргә кирәк.

– Фатирлар төзү идеясе 2005 елда ук туган иде инде. Шул чакта беренчесен Киров өлкәсеннән килгән ветеринария табибы Резидә Шихованга төзедек. Ул гаиләсе белән шунда яшәп, эшләп, лаеклы ялга чыкты. Килешүнең шарты бик гади: ун ел хуҗалыкта эшлә генә. Бер дигән әзер йортка, бер тиен түләмичә, кереп яшисең, ун ел хуҗалыкта эшләгәч, ул үзеңә кала. Тик ул чакта бу шартлар белән кызыксынучы табылмады. Сорачу булса, тагын төзергә исәп бар иде дә... – ди ул. – Аннан соң 2012 елда Илдар Галимуллинга төзедек. Хәзер дә хуҗалыкта эшли, баш энергетик. Авылдашыбыз Иреккә төзелгәнендә ветврач Рәис гаиләсе белән берничә ел яшәде дә күчеп китте. Аның урынына Кукмара районыннан өч балалы гаилә килде. Гөлшат – хуҗалыкта зоотехник-селекционер, бер дигән белгеч.

Гөлшатның аягы җиңел була. Әлләдөньядагы вазгыять үзгәрү дә сәбәпче буламы, хуҗалыкка бер-бер артлы эш һәм фатир сорап килүче белгечләр арта. Лениногорск районыннан күчеп килгән Максимовларның гаилә башлыгы Максим – баш агроном, тормыш иптәше Анастасия зоотехник булып эшли. Күптән түгел балалары туган. Грачевлар исә «Кызыл юл»га Ютазы районыннан күченеп кайткан. Леонид тегермәндә эшләсә, Светлана комплекс белән идарә итә, терлекчелек буенча урынбасар.

– Мөлимнән кайткан Галимовларның терлекчелек өлкәсендә, комплекста эшләү тәҗрибәсе зур иде, алар шуңа күрә коллективка да бик тиз кереп китте, – ди Фердинанд. – Илмир – ортопед, ягъни тояк караучы, бу һөнәр иясенең остаһлыгыннан бик күп нәрсә тора, бик кирәкле белгеч. Җәмәгате Лиза бозаулар карый.

Күптән түгел генә түбә астына кергән җиденче фатирның да иясе бар икән инде.

– Киләм, кайтам дигәннәребез дә әйрәнеп, сынап алырга тырышабыз, – ди җитәкче. – Яңа төзелә торган йортка өч яшь балалы гаилә Казаннан күченеп кайтырга тиеш. Берсе – энергетик, берсе – икътисадчы. Кирәкле белгечләр. Яшьләр кайту икеләтә сөенечле бит: яңа төзелгән мәктәп-балалар бакчалары бушый барган заманда, безнең комплексның бакча ягы тулы: 15 балага исәпләнгән иде, бүген 15 бала йөри. Башлангыч мәктәпкә дә өмет бит алар... Төзергә дә төзергә инде фатирларны. Туктар исәп юк.

Тик рәисне шунысы бина борчый: әлегә авылныкылар шәһәргә тартыла. Читтән килгәннәр бирелә чит булмаса да, медальнең икенче ягы да бар шул...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА



НАМУС КУШКАНЧА

Ватан хакына

«Минем белән бик нык горурланырсың әле, әни». Хәрби операциягә киткән егетләр һәркайсы әнисен шулай дип тынычландырырга тырышкан. «Татарстан Геройлары аналары» күргәзмәсе ачылышына килгән аналар улларының соңгы сүзләрен искә төшерде. Күргәзмәдә илне саклаучы егетләрнең, шулай ук яуда батырларча һәлак булган 20 солдатның аналары портреты тәкъдим ителде.

Картиналарда улларының солдат киемен кигән аналар һәм аларның хатлары урын алган. «Улым, күз нурым! Якты дөньядан китүеңә дә күпме сулар акты. Күңел һаман сине көтә… «Батыр үзе өчен туар, кеше өчен үләр», – диләр татар халкында. Күңеле, намусы шулай кушкан кешегә берни дә комачауламый… Без сине бик юксынабыз», – диелгән хатларның берсендә. Икенче бер ана хатны улының туган көнендә язган: «Кадерле улым, сиңа бүген 37 яшь тулган булыр иде. Сине югалтуга елдан артык вакыт үтте. Җанга «әни» дигән сүзең җитми. Йөрәк телгәләнә. Синсез ничек яшим?»

Татарстандагы «Офицер хатыннары» оешмасының вәкаләтле вәкиле Оксана Бородина әйтүенчә, аналарның һәрберсенең үз ярасы: югалту ачысы, кош теле кадәр булса да хәбәр көтү… Кайберләренең айлар буе юньләп йоклаганы юк. Әлеге күргәзмә барлык әниләрне берләштерергә ярдәм итәчәк, дип ышана ул. Әлегә 20 портрет тәкъдим ителсә, тиздән тагын җидесе әзер булачак. Күргәзмәдә улы хәрби операциядә булган һәр ана катнаша ала. Оештыручылар бу проект белән гаилә кыйммәтләрен, иң зирәк, иң яхшы әниләрнең Россиядә яшәвен күрсәтергә теләгән.

Чарада катнашкан Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева һәрбер анага рәхмәтен җиткерде. Шулай ук ул Татарстан Хөкүмәт йортында, «Ватанны яклаучылар» дәүләт фондында солдат аналарына багышланган даими чараларның Җиңүне якынайтырга булышуын әйтте.

Улларын югалткан әниләргә никадәр генә авыр булса да, алар күргәзмәдә катнашырга, фотога төшәргә көч тапкан.

– Мондый чараларны калдырмыйбыз. Чакырган җиргә барырга тырышабыз. Улыбыз Дамир Гыйлемханов «Россия Герое» медале белән бүләкләнде. Үзе укыган 42 нче мәктәптә аңа багышланган махсус почмак бар. Киемнәрен, истәлекләрен шунда бирдек. Мәктәптә, аңа багышлап, мемориаль такта элделәр. Хәзер улыбызга 24 яшь тулган булыр иде, – диде Ленария апа, күз яшьләрен эченә йотып. – «Ватанны яклаучылар» фондында гозеребезне тыңлыйлар. Улымның телефонын табып бирделәр. Рәхмәт, үзе бер истәлек бит ул.

Ленария апа хаҗ кылган, әмма күңеленә тынычлык иңмәгән әле. Дамирын ул шук, әмма сүзне тыңлый иде, дип искә алды. Татарча да, русча да яхшы белгән егет. 2019 елда Казан политехника көллиятен тәмамлап, кулына диплом алырга өлгермичә армиягә киткән Дамир. Башта Хабаровск краенда, аннан Ростовта хезмәт иткән.

– «Әни, контракт төзергә җыенам, син минем белән горурланырсың әле. Үземне бары яхшы яктан күрсәтермен. Алда һөнәри яктан үсәргә мөмкинлек бар. Тора-бара Казанга күченергә була. Танк училищесында укып, офицер булырмын», – диде. 2020 елда октябрьдә ялга бер мәртәбә кайтып китте дә шуннан соң башка очрашырга насыйп булмады. Беренчесенең срогы тәмамлангач, икенче тапкыр контракт төзеде, – дип сөйләде Ленария Гыйлемханова.

Әти-әниләрен борчымас өчен, февральдә Кавказга командировкага чикне сакларга җибәрәләр, дип хәбәр итә ул. «Миллерово хәрби шәһәрчеге» дигән сүзне дә әйтә. Якыннары, картадан карагач кына, Дамирның кайда икәнен чамалый. Соңгы тапкыр 2022 елның 2 мартында кибеткә кергәч: «Әни, ашыйсыбыз килә, картага акча сала алмыйсыңмы?» – дип шалтырата. 7 мартта һәлак булса да, гаилә ай буе билгесезлектә яши. Интернеттагы язманы укыгач кына, Дамирның һәлак булганын беләләр. 2 апрельдә Гыйлемхановларга Ростов өлкәсеннән: «Бер солдатның янган җәсәде кайтты, ДНК анализы бирергә кирәк», – дип шалтыраталар. Кызганыч, әтисенең туган көнендә – 13 апрельдә улының гәүдәсенең көлен кайтаралар. Саубуллашу танк училищесында үткән.

Чарага Кукмара районыннан дүрт ана килгән иде. Зур Кукмара авылында яшәүче Дамира Кашапованың да улын уйламаган минуты юк.

Ильмир, танк училищесын тәмамлап, Приморье краена киткән, шунда булачак тормыш иптәше Нинаны очраткан. Әлеге күргәзмәгә ул да кызлары белән килгән иде. Кечесе Әминәгә – 4 яшь. Әтисен сагынып елый икән балакай. Олысы үзенеке булмаса да, аңа да үз фамилиясен биргән. Барысын да тигез күргән гаилә башлыгы. Ильмирның җәсәден Кукмара шәһәренең Дан аллеясына күмгәннәр. Каберенә якын буласым килә дип, Нина августта кызлары белән Казанга күченгән. Хәрби операция башлангач, Ильмир хатынына: «Мин – Россия армиясе офицеры. Ватан алдында бурычымны үтәргә, сезне, илебезне якларга тиеш», – дигән.

Ильмир, җае чыккан саен, әнисе белән хәбәрләшеп торган. «Әни, кайгырма, бәла буласы урыннан, күңелем сизеп, күченеп китәм мин», – дигән. Белгән догаларын укып йөргән ул. Тик соңгысында котыла алмаган.

– Дронны күреп, иптәшләренә танк астына качарга әмер биргән. Үзе шуның артыннан посадкага йөгергән. Ядрәләр урман полосасына чәчелгән. Менә шунда кыйпылчыгы Ильмирга да тигән. Башка иптәшләренең гомерен саклап калган. 2022 елның 7 августта улыма 37 яшь тулды, ә 19ы көнне һәлак булды, – ди Дамира ханым. – Кечкенә чагында тиктормас иде ул. Тугач та ярты ел йокламады, 7 айдан тәпи китте. 1,5 яшьтә тимераякка басты. Егыла да тиз генә торып, яңадан йөгерә иде. Куркуны белмәде. Менә шулай батыр йөрәкле булып, арабыздан китеп тә барды.

«Татарстан Геройлары аналары» күргәзмәсен Россия Дәүләт Думасына җибәрергә җыеналар. Шуннан соң аның белән республика районнарында да танышып булачак.

Сәрия МИФТАХОВА

Ленария Гыйлемханова: «Улыбыз Дамир, үземне бары яхшы яктан күрсәтермен, диде».

Анна Арахамия

Дамира Кашапова: «Улыбыз Ильмир курку белмәде».



Хәтер

Батырлык үрнәге

«Тарихи хәтерне саклау – безнең төп бурычыбыз». Республиканың яшь гвардиячеләре шулай ди. Казанның М.С. Устинова исемендәге 102 нче гимназия ишегалдында яшь гвардияче геройларга багышланган мемориаль комплекс ачылды. Чара «Бердәм Россиянең Яшь гвардиясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының 18 еллыгын бәйрәм итү кысасында узды.

Республиканың яшь гвардиячеләре грант акчаларына Советлар Союзы Герое, Бөек Ватан сугышы елларында Краснодон (ЛНР) территориясендә эшләгән «Яшь гвардия» фашистларга каршы яшерен оешмасы лидерларының берсе Олег Кошевойның бюстын яңадан торгызганнар. Алай гына да түгел, янәшәдә тагын биш Советлар Союзы Герое – Ульяна Громова, Любовь Шевцова, Сергей Тюленин, Иван Земнухов һәм Иван Туркеничның портретлары белән мемориал да эшләгәннәр.

«Тарихи һәм бүгенге заманда бик кирәк вакыйга». Мемориаль комплекс ачуны «Бердәм Россия» партиясенең Татарстан төбәк бүлеге Секретаре, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әнә шулай дип атады.

– Әлеге һәйкәлне яңартып, йөрәкләребездә хәтерне яңартабыз. Мемориалны ачу – безнең күпмилләтле халыкның, шул исәптән яшь гвардиячеләрнең Бөек Ватан сугышы елларындагы батырлыклары турындагы хәтерне саклауга керткән өлешебез. Бүгенге тормышыбыз һәм киләчәгебез өчен гомерләрен биргән бу яшь кешеләргә хөрмәт күрсәтәбез, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Бу һәйкәл 1980 нче еллар ахырында куелган. Шул вакыттан бирле бер тапкыр да ремонтланмаган. Аны яңарту – изге, игелекле эш. Бигрәк тә сезнең инициатива һәм сезнең катнашу белән. Дошман тылында булган яшь гвардиячеләр Бөек Җиңүне якынайту өчен мөмкин булганның барысын да эшләгән. Бу мемориал геройларыбызның исемнәрен мәңгеләштерү эшен лаеклы дәвам итә.

Фәрит Мөхәммәтшин яшьләргә тарих, тылда фидакарь хезмәт куйган һәм үз-үзләрен аямыйча сугышкан батырлар язмышы белән кызыксынуларын теләде.

– Бөек Ватан сугышы елларында яшьләрнең батырлык темасы бик мөһим. Ул бары тик юбилей даталарында, ниндидер бәйрәмнәрдә генә искә алынырга тиеш түгел, – диде парламент җитәкчесе.

Татарстан Яшь гвардиясенең төбәк штабы җитәкчесе Руслан Шиһабетдинов сүзләренә караганда, аларның төп бурычы – тарихи хәтерне саклау:

– Яшь буын буларак, безнең бурыч – Ватаныбызны саклаучылар истәлеген хөрмәтләү генә түгел, ә яшьләрне үз тарихларына карата хөрмәт белән тәрбияләү. Бүген тарих кабатлана. Бөтен илдән яшь гвардиячеләр нацизмга каршы көрәшкә үз өлешен кертә, активистлар гуманитар миссияләр белән яңа төбәкләргә бара, андагы халыкка һәм безнең хәрбиләргә ярдәм итә. Апрельдә команда белән беренче тапкыр Краснодон шәһәренә бардык, яшь гвардиячеләр геройларына багышланган музейда булдык. Ул композицияләрне карап, аларның үз куллары белән язылган антларын күргәч, күзләргә яшь килде.

> Яшь гвардия – чыннан да, батырлыкның чын үрнәге. Геройларыбызның исемен мәңгеләштерү – иң мөһим бурычыбыз. Без бу юнәлештә эшне дәвам итәргә ниятлибез. Яшь гвардияче исемен горурлык белән йөртәчәкбез.

Казанның Киров һәм Мәскәү районнары башлыгы Сергей Миронов та яшь гвардиячеләргә җылы сүзләрен җиткерде:

– Яшь армиячеләребез, сезгә карап, үрнәк алалар. Сезнең өчен «Ватан», «патриотлык», «бурыч» сүзләре – буш сүзләр түгел. Мемориаль комплексны ремонтлау – безнең районның гына түгел, шәһәрнең дә патриотик хәрәкәтен үстерүгә мөмкинлек бирә, – диде ул.

102 нче гимназиядә Фәрит Мөхәммәтшин Яшь гвардия волонтерлары республика районнарының җирле бүлекчәләре җитәкчеләре белән очрашты.

– Хәрбиләргә һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтүче волонтерлар – һичшиксез, геройлар. Тормышларын куркыныч астына куеп, алар гуманитар йөкләрне озата баралар, яңа төбәкләрдә яшәүче халыкка ярдәм итәләр, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Ләйсән САФИНА

tatarstan.ru

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Ясалмалык

Ясалма акыл турында сүз чыкса, гади кеше гадәттә кул селтәп кенә куя. Әллә нәрсәләр белән баш катырма әле, янәсе. Буй җитмәслек ераклыкта өерелгән гайре табигый нәрсә кебек тоела ул. Әле андый нәрсәләр безгә килеп өлгәшкәнче әллә күпме сулар агар, әллә ничә пот тоз ашалыр. Үзебезнең аяк астындагы мәсьәләләрне хәл итеп бетерергә вакыт җиткереп булмый. Ә сез монда «ясалма акыл»…

Ясалма акыл дигән төшенчәгә без артык зур мәгънә дә салабыз бугай. Шуңа ул могҗизаның бер төре шикеллерәк күренә. Чынында хәлләр аз гына башкачарак. Ясалма акылдан без әллә кайчаннан бирле файдаланабыз инде. Алай гына да түгел, без шуңа нигезләнгән ясалма әгъзалар кулланабыз.

Иң гади нәрсәдән башлыйк. Кичтән сәгатьне иртәнге алтыда шалтырарга куябыз да ятып йоклыйбыз. Ул уята. Әлбәттә, моны бүгенге күзлектән карап «ясалма акыл» дип булмый кебек. Әмма сәгать безгә кирәкле вакытта шалтырый. Ә бит узган гасыр башында шундый һөнәр булган – аерым бер кеше иртә белән, тәрәзә яки ишек шакып, эшчеләрне уятып йөргән. Бүген шул һөнәрне йодрык зурлыгындагы бер будильник алыштыра.

Элек бездән тапкырлау таблицасы ятлаталар иде. Математиканың дүрт гамәлен белү мәҗбүри, чөнки тормышның кайсы гына өлкәсенә тотынсаң да, шулар белән очрашасың: кушарга, алырга, тапкырларга, бүләргә мәҗбүр буласың. Кайбер гамәлләрне уйда гына эшләп булмый, кәгазьдә хисапларга туры килә. Ни генә әйтсәң дә, бу – акыл көче таләп итә торган нәрсә. Ә калькуляторлар пәйда булгач, мондый белемнәрнең кирәге кимеде. Нинди генә саннар белән эш йөртсәң дә, калькулятор барысын да чутлап чыгара. Монысы инде – чынлап та, ясалма акылның бер баскычы. Хәтта иң белемле кеше дә сәгатьләр буе баш вата торган нәрсәләрне ул секунд эчендә башкара.

Компьютерлар пәйда булгач, без кирәкле нәрсәләрне интернеттан эзли башладык. Китапларны, әйтик, элек ничек эзли идек… Китапханәгә барасың, шүрлекләрне актарасың, кирәкле кебек китапны алып ачып карыйсың… Ә хәзер эзләгеч графасына үзеңә кирәкле китапның исемен яки темасын, яки берәр өзеген кертәсең дә мизгел эчендә җаваплар хасил була. Менә монысында инде чын-чынлап ясалма акыл хәрәкәт итә. Ул эзләүченең кайда яшәвен, нинди телдә язуын, моңа кадәр нәрсәләр эзләгәнен һәм тагын әллә күпме вак-төякләрне исәпкә алып эшли. Интернеттан реклама күрсәтү җайланмалары да шул нигездә эш итә: әгәр син көрәк эзләгәнсең икән, кайсы сайтны ачсаң да, көрәк рекламасы килеп чыга. Моның белән кызыксынмавыңны аңлагач, азая, туктый.

Хәзер инде ясалма акылга нигезләнгән чатлар пәйда булды. Болары теләсә кайсы соравыңа тулы җавап бирә ала. Әйтик, быел бәрәңгене ничек утыртырга икәнен сорасаң, ул сиңа тулы бер белешмә язып бирә. Җөмләләре кайбер журналистларныкыннан да әйбәтрәк. Гадәттә, җаваплары да дөрес була. Ул бары тик төгәллек таләп ителгән мәгълүматларда гына хаталана. Әлегә шулай. Киләчәктә бер хатасыз да эшли башларга мөмкин. Чит илләрнең һәм русларның бик күп сайтларында ясалма акыл нигезендә язылган мәкаләләр урнашканлыгын исәпкә алсаң, ул бик күп копирайтерларны эштән бушатырга мөмкинлеген аңлыйсың. Хәзер хәтта мәктәп балалары да өй эшләрен шуның ярдәмендә эшли ала. Исәп-хисаплар ясый ул, китапларның кыскача эчтәлеген чыгарып бирә, сочинениеләр яза. Грамматик, орфографик, стилистик хаталарны тикшерә.

Бер сүз белән әйткәндә, ясалма акылга корылган чатлар бүген көндәлектә килеп туган теләсә кайсы мәсьәләне чишүдә ярдәм итә ала. Баш авыртканда нәрсә эшләргә? Ул сиңа бөтен мәгълүматны китереп сала. Төгәллек кертергә кирәк булса, сораулар бирә: «Башыгызның кайсы өлеше авырта? Ничек авырта? Кайчаннан бирле?» Һәм шул рәвешле ачыклык кертәкертә дә тиешле ысулларны тәкъдим итә. Кыяр тозларга телисең икән – рәхим ит. Иске кадакларны эшкә яраклы итәргә телисең икән – сора гына. Тормышның бөтен өлкәсендә ул ярдәмче. Шул рәвешле, ясалма акылны без хәтсездән кулланабыз инде. Үзебез генә аңлап бетермибез. Ул кайдадыр читтә, еракта, буй җитмәслек биеклектә түгел, ул – безнең көндәлектә.

Ясалма әгъзаларны кешелек аннан да алдарак куллана башлаган. Автомобиль, мәсәлән. Кер юу машинасы. Балта, пычкы, көрәк… Таяктан башланган ул. Таяк кешенең кулын да озынайткан, йодрык булып та, тояк булып та хезмәт иткән. Шуларның иң киңкырлысы, әлбәттә, компьютер һәм телефон. Берәр көнгә генә мобильнигыгызны читкә алып куегыз, сез аралаша да алмыйсыз, яңалыкларны да белмисез, финанс операцияләрен дә башкара алмыйсыз. Ике кулсыз калган кебек буласыз. Аның ясалма әгъза икәне нәкъ менә шул вакытта чагыла да инде.

Кешелек үзенең юл башында ук ясалма юлдан киткән инде. Кулына таяк алмаган булса, бәлки ул үзенең сикерү сәләтен арттырыр яки кулын озынайта алыр иде. Бәлки, телефоннарга мохтаҗлыгы булмас, телепатия ярдәмендә аралашыр иде. Хәзер әйтеп булмый. Ул бүтән юлны сайлаган. Ясалмалык – аның бөтен булмышында хәзер. Ясалма акыл кебек үк бераздан ясалма хисләр төшенчәсе барлыкка килә икән, моңа һич тә аптырыйсы түгел. Шул рәвешле кешелек үзен үзе төзи. Кеше үзен үзе ясый. Һәм үзенең ясалма икәнен үзе дә аңламый.

ЭШМӘКӘР АЛЬБЕРТ ХӘЯЛИЕВ:
«АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНЫҢ ҖАНЫ БАР»

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кайбыч

Һөнәре буенча финансист, гомере буе шәһәрдә яшәгән Альберт Хәялиев, тугыз ел элек авылга кайтып, агробизнес ачып җибәрә. Бу вакытта аның терлекчелек буенча да, игенчелек буенча да күзаллавы булмый диярлек.

Ләкин ата-бабаларының туган нигезен һәм кече Ватанын саклау теләге барыннан да көчлерәк булып чыга.

– Унбиш-егерме ел элек миңа, авыл хуҗалыгында эшләячәксең, дисәләр, бик нык гаҗәпләнер идем. Ә авылга кайту тарихым бабайның Кошман авылындагы нигезен саклап каласы килүдән башланды. Әлеге йортта минем әти һәм аның туганнары үскән. Туганнарым участокны сатарга теләк белдергәч, очрашу урыны буларак калдырыйк, дидем. Башта йорт тергездек, аннан аның койма-капкасын булдырдык, мунча да җиткердек… Тора-бара авылга кайту тагын да ныграк ошый башлады, тартыла башладым. Шул вакытта агробизнес проектлары белән кызыксыну барлыкка килде. Шуннан соң дуслар киңәше белән витаминлы-гранулалы он ясау техникасы турында китап укыдым. Гап-гади авыл китапханәсеннән алынган иске генә китап иде, тик актуальлеген бүген дә югалтмаган зур хәзинә булып чыкты ул.

Менә шулай итеп туган нигез чакырып кайтарган да авылга төпләндереп калдырган Альберт Хәялиевны. Бүген ул – өч компанияне берләштерүче авыл хуҗалыгы группасы җитәкчесе. Беренчесе – терлекләр һәм кош-кортлар өчен югары аксымлы азык кушылмасын җитештерүче «Сл-агро» оешмасы, икенчесе – 500 мөгезле эре терлеге һәм 2 мең гектар сөрүлек җирләре булган «Туган як – агро» хуҗалыгы һәм өченчесе – тәүлегенә 2,5 мең тонна сөт эшкәртүче «Сл-сөт» заводы.

Җитәкчене авыл хуҗалыгына алып килгән, якынайткан югары бета-каротинлы витаминлы-үләнле гранулаларны кошчылык һәм атчылык белән шөгыльләнүчеләр аеруча ярата икән.

– Без печәнне югары температурада киптереп, аның барлык файдалы үзлекләрен саклыйбыз. Үлән онында файдалы үзлекләр ун тапкыр күбрәк. Иң мөһиме: аларны берничә ел сакларга мөмкин. Элек мондый үлән онын һәр колхозда ясаганнар. Ләкин бүген терлекләр өчен бик файдалы бу продуктны Татарстанда нибары ике оешма җитештерә. Шуларның берсе – без, – ди ул.

Колаңгы тимер юл станциясе бистәсендә яңа цех ачу исә авыл хуҗалыгының башка тармакларына да юл ача.

– Күп нәрсәләргә башкача карый башладым, – ди ул. – Авыл хуҗалыгы нәтиҗәле эшләсен өчен, тулы бер цикл кирәк. Ягъни чималдан алып кибет киштәсенә кадәр юл узарга тиеш ул. Шуны күздә тотып, күрше авылдагы ташландык хәлдәге колхозның җирләрен яңарттык, техникалар сатып алдык, фермаларга реконструкция ясап, сыерлар кайтарттык. Уңышлы бизнес өчен чималны эшкәртү дә кирәк. Шулай итеп, сөт эшкәртү заводы барлыкка килде.

Әлеге сөт заводы турында газетабызның узган саннарында язган идек инде. Шуңа күрә анысына озаклап туктап тормабыз. Ә менә җитәкченең киңәш буларак әйткән сүзләрен укучыларыбызга да җиткерергә булдык.

– Күпчелек авыл каймагы белән кибет каймагын (сметана) бутый, – диде Альберт Хәялиев. – Кибет каймагында кашык басып торырга тиеш, дип уйлыйлар. Аңарда кашык бервакытта та басып торырга тиеш түгел. Сметана – әчкелтем сөт продукты, аңа оеткы салына. Ә каймакка оеткы бервакытта да салынмый. Ул – майлы сөт өсте. Сметана агып төшәргә һәм тигез өслек булдырырга тиеш. Элек без аны эчә идек. Әгәр кибеттән алган сметанада кашык басып тора икән, димәк, аны куертыр өчен крахмал кушканнар. Йод тамызып тикшереп карарга мөмкин. Әгәр ул таралып китә икән, димәк, сметананың составында крахмал бар дигән сүз.

Эш, көндәлек мәшәкатьләр, бизнес белән янып-көеп йөрсә дә, авылда калуының төп сәбәбе башкада, ди эшмәкәр.

– Минем максат – акча артыннан куу түгел, – ди ул. – Авыл хуҗалыгында бизнестан тыш, башка кыйммәтләр дә бар. Анда җан бар. Кешелек кыйммәтләре, җан һәм рух җирдә калды әле. Авылда кешеләр дә башка, табигать тә матуррак, һава да чистарак. Хәзер инде минем Казанга китәсем дә килми. Хатыным – Себер кызы. Ул да авылга ияләште, табигатен дә, кешеләрен дә ярата. Балалар инде зурлар. Ялларга алар да бик теләп кайтып йөриләр. Менә шулай, бабам нигезе барыбыздан да авылны яраттырды.

Зөһрә САДЫЙКОВА

БАТЫР ЙӨРӘК

Уникаль очрак

80 секунд вакыт… РКБ һәм МКДЦ табиблары шушы кыска гына бер мизгел эчендә йөрәгендә тромб табылган йөкле хатын-кызның һәм карынындагы нарасыйның гомерен саклап калган. Республика табиблары ясаган чираттагы уникаль операция барыбызны таң калдырды.

tatar-inform.ru

21 яшьлек Ксениянең йөрәге туганда ук зур сынауларга дучар була. Өч яшендә аңа беренче катлаулы операция ясыйлар. Шул көннән башлап ул даими рәвештә кардиологка күренеп тора. 16 яшендә йөккә уза ул. Әмма баласы төшә. 17 яшендә Ксения кабат әни булачагын белә. Әмма бу йөклелегенә дә озак сөенергә насыйп булмый. Табиблар Ксениянең йөрәгендә тромб барлыгын ачыклый. РКБның акушерлык һәм гинекология буенча баш табибы Нигина Нигъмәтуллина сүзләренә караганда, бу – бик авыр очрак. Ксениянең йөкле булуы хәлне тагын да катлауландырган.

– Тромб теләсә кайсы вакытта өзелергә мөмкин бит. Бу исә – анага да, карындагы балага да үлем яный дигән сүз. Бер төркем табиб җыелып сөйләшкәннән соң, кызга кичекмәстән операция ясарга кирәк дигән карарга килдек. Башка вакытта бу операция ясалма кан әйләнеше булдырып ясалыр иде. Әмма безгә бит карындагы сабыйны да саклап калырга кирәк. Шуңа күрә безнең бер генә юл калды: 80 секунд эчендә йөрәктәге тромбны алып, вакытлыча туктатып торылган кан әйләнешен кабаттан эшләтеп җибәрү, – дип искә ала ул табиблар могҗиза тудырган көнне.

Бәхеткә, операция уңышлы чыга: табиблар бер мизгел эчендә ананы да, аның сабыен да үлемнән саклап кала. Шулай да пычак астына керү үзенекен итә: ике айдан Ксения баласын югалта.

– Аның шулкадәр әни буласы килде. Тагын бер йөклелеге өзелүен белгәч, Ксениягә: «Син, һичшиксез, әни булачаксың!» – дип сүз бирдем. Өченче йөклелеген инде ул беренче көннән үк табиблар күзәтүе астында уздырды. Безнең перинаталь үзәктә генә дә дүрт ай ятып чыкты ул. Ниһаять, узган атнада, 37 атналык булып, 2,8 килограмм авырлыктагы сау-сәламәт малай дөньяга аваз салды, – ди Нигина Нигъмәтуллина.

Ксениянең бүген ни дәрәҗәдә бәхетле икәнен сүз белән генә аңлатып бетереп булмас кебек. Иң зур хыялының озын һәм сикәлтәле юл узып чынга ашуына атлаган саен шөкер итә ул.

– Улымның туар көнен көнләп түгел, минутлар санап көттем. Йөклелекнең һәр атнасы узган саен, җиңел сулап куя идем. Бу баламны да югалтмасам ярар иде, дип борчылдым. Миңа әни булу бәхетен бүләк иткән һәр табибка, янымда булган һәркемгә гомер буе рәхмәтле булачакмын, – ди Ксения, күз яшьләрен тыя алмыйча.

Аның туганыдай якын кешесенә әверелгән Нигина Нигъмәтуллина исә биргән вәгъдәсендә торуына шатланып бетә алмый.

– Операциягә керер алдыннан Ксения миңа хәзерге вакытта исән булган бердәнбер якын кешесе – үги әтисенең телефон номерын бирде. «Уянмасам, аңа бу хакта шалтыратып әйтерсез», – диде. Мин аны: «Бар да яхшы булачак. Бездән син сау-сәламәт килеш, кулыңа яңа туган сабыеңны тотып, бу дөньядагы иң бәхетле кеше булып китәчәксең», – дип сүз бирдем. Шулай булды да, – ди Нигина Нигъмәтуллина.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Бәйгедән соң

Нечкәбилләр бил алыша

«Нечкәбил» хатын-кызлар республикакүләм бәйгесе быел 18 нче мәртәбә үткәрелде. Финалга төрле районнардан 12 ханым үткән иде. Аларның һәрберсенең гаиләсенә сокланырлык!

Финалда катнашучыларны котларга дип, Мәскәүдән кайткан Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова әнә шулай диде.

– Татарстанда үрнәк гаиләләр яши. Дәүләт Думасында эшли башлагач, күпне аңладым. Бездә гаилә кыйммәтләрен саклау өчен бик күп эшләр башкарыла. Гаилә ул – әби-бабай, әти-әни, балалар һәм оныклар. Биредә ярату, бер-береңне аңлау яши. Гел шулай булсын, – диде ул.– «Нечкәбил»не оештырган Изольда Жуйковага рәхмәт. Күпме гаиләләрне берләштерде.

Изольда Жуйкова исә рәхмәтенең зурысын Татарстанның Беренче Президенты, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевкә әйтә.

– Әгәр ул безнең фестивальне куәтләп алмаса, бүгенгә кадәр килеп җитәр идеме икән? Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка да, барлык ярдәм кулы сузучыларга да рәхмәтлемен, – ди ул. – Без бу бәйге аша үрнәк гаиләләрне барлыйбыз. Һәр гаиләдә төрле традицияләргә юлыгабыз. Узган елгы бәйгедә нәселләрендә аерылышу булмаган гаилә белән таныштык. Барыгызга да шуны телим.

Бу бәйгенең исемен ишеткәч, нечкә билле ханымнар бәйгеседер диярсез. Юк! Монда иң тырыш, гаиләсе өчен янып яшәүче, үзенең бәхет серен башкалар белән бүлешергә әзер торган ханымнар катнашты. Алар үз милләтенең иң күркәм гореф-гадәтен сәхнәләштергән иде. Чүпрәле районының Алешкин-Саплык авылыннан Наталья Клементьева гаиләсе чуашларда балага исем кушу йоласын башкарды. Азнакайдан Лия һәм Алмаз Закировлар «Самавыр» бәйрәмен күрсәткәндә, Казан сәхнәсенең идәннәре селкенде. Бик матур чыгыш иде ул. Аларның милли киемнәре, җыр-биюләре күңелләрне айкады. Түбән Камадан килгән Куканослар гаиләсе дә шаккатырды. Аларның мәхәббәт тарихлары үзенчәлекле. Владимир, «Нардуган» ансамбле артисты Гөлназның чыгышын караганнан соң, аңа гашыйк була. Фойеда көтеп ала да бик ошатуын әйтә. Егет эшне озакка сузмый – икенче көнне кияүгә чыгарга тәкъдим ясый. Менә шулай итеп гаилә учагы кабына. Алар хәзер өч кыз үстерә.

Бәйгедә 1 нче урын алган Шәймөхәммәтовлар (Балтач), 2 нче урын алган Шәйхәйдәровлар (Кама Тамагы районы Антоновка авылы), өченче урынны яулаган Нурисламовлар (Саба районы Тимершык авылы) гаиләләре җиңүнең ничек бирелгәнен үзләре генә беләдер.

– Бәхетемне Балтачта таптым, – ди Мамадыштан килен булып килгән Рания Шәймөхәммәтова. – Бу бәйгедә катнашуыма бик шатмын. Минем өчен җан аткан һәркемгә, иң беренче чиратта гаиләмә чиксез рәхмәт.

Ә инде – гран-прига лаек булган гаилә – Чирмешәннән. Зилә Латыйпова ире Альберт белән 4 бала үстерә.

– Бу бәйге безнең гаиләне тагын да якынайтты, – ди Зилә. – Ирем белән 13 ел элек гаилә кордык. Ул – эшмәкәр, минем дә – үз эшем. Көннең узып киткәнен дә белми идек. Чирмешәндә 3 гектар виктория һәм кура җиләге басуларыбыз бар. Табигый шоколадлар җитештерәбез. Әле бит өйдә 4 бала да бар. Бу бәйгедә катнашырга теләвемне Альбертка җиткердем. «Әзерләнергә кирәк, син үзеңнең телефоныңда булган видео, фотоларны барла әле», – дидем. Кичкә зур гөлләмә тотып кайткан. Теге фото, видеолар аша күпне аңлаган иде.

«Һәр бала үз ризыгы белән туа» диюләре Латыйповларга туры килеп тора. Һәр бала белән декретта утырганда, Зиләгә төрле идеяләр килә. Ипи дә пешерәләр, шоколад та ясыйлар, җиләк тә үстерәләр. Инде менә конфет ясый башлаганнар. Алары да – табигать нигъмәтләреннән.

– Республика күләмендә узган бәйгедә гран-прига лаек булырбыз дип уйлап та карамаган идем. Күңелдә «3 нче урынны булса да алсак иде» дигән теләк булды булуын. Ахырга кадәр җиңүемә ышанмадым, – ди Зилә. – Өйгә бик рәхәт хисләр белән кайтып киттек. Ә бит бу бәйгедә гел сынауларга юлыгып тордым. Зона турында бер күзем йомылды. Җил бәрде. Күзлек киеп чыгыш ясадым. Ярымфиналга килгәндә, тавышым бетте. Минем өчен бертуган апам сөйләп торды. Бер уйласаң, кулны да селтәп була иде. Тик без алга барырга күнеккән. Ирем ныклы терәк булды. Иңне иңгә куярлык кешең булу – зур бәхет, – ди Зилә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

СИН ҮЗЕҢ ДӘ УРАЛ ТАВЫ КЕБЕК

Автор фотосы

Шәхес

Бөтен гомерен космонавтика һәм авиация өлкәсенә багышлаган Урал Закировка 90 яшьлек юбилее уңаеннан әнә шундый бәя бирделәр. «Җиһангирлар» инициатив төркеме тарафыннан Казан шәһәренең 171 нче лицеенда үткәрелгән бу кичә «Урал Закиров белән – 108 минут!» дип аталды. «Ни өчен?» – дигән сорауга залдагы тамашачылар шундук дөрес җавап бирделәр. 1961 елның 12 апрелендә беренче космонавт Юрий Гагаринның тарихи очышы нәкъ менә 108 минут дәвам итә. Данлы эшләр эшләп тә, тыйнак кына гомер кичергән милләттәшебез турында күпләр белеп тә бетерми кебек.

Балачак

Урал Нуриевичның Свердловск шәһәре милиция бүлегендә оперуполномоченный булып эшләгән әтисе Нурисламны, партия кушуы буенча, Татарстанга күчерәләр. Гаилә сугыш башланганчы башта – Казанда, аннан бүгенге Яшел Үзән районының Төньяк Норлат авылында яши. Урал абый бу авылны бик яхшы хәтерли, чөнки ул монда беренче сыйныфка укырга китә. Бер елдан язмыш аларны Базарлы Матак авылына китереп ташлый. Нәкъ менә шунда бәләкәй малайның киләчәген билгеләүче бер вакыйга була. Авылга «кукурузник» дип аталган, фанердан ясалган ике кешелек самолет очып килә. Әлбәттә инде, бар халык могҗиза карарга җыела. Ә Уралның әтисе, нәрсә дисәң дә, җитәкче урында эшли бит, улы белән бергә самолетта очып алырга да җай таба. Нәкъ шул вакытта малай биеклекнең нинди ләззәтле булуын тоя да инде. Шунда ул зәңгәр күккә, биеклеккә һәм җилдән җитез тизлеккә гашыйк була.

1944 елда әтисе Эстониягә китә. Малай журналист булып эшләүче әнисе Әминә белән кала. Нәкъ бер елдан сугыш тәмамлана. Җиңү бәйрәме төнендә ул төш күрә. Очсыз-кырыйсыз зәңгәр күктә йолдызлар... Менә ул аларга таба якынлаша... Хәтта куллары белән тотып та карый сыман. Бу вакытта Уралга 12 яшь була.

Үсмерчак

Урал Казанда әнисенең апасы Наилә Хамматовада («Социалистик Татарстан» газетасының легендар редакторы Шәмси ага Хамматов гаиләсендә) фатирда яши. Шуңа күрәдер инде, ул «Ватаным Татарстан» турында бик бай истәлекләр саклый, бүген дә аны «иң яраткан газетам» дип атый. Апасы егетне иң алдынгы уку йортларыннан саналган 19 нчы мәктәпкә урнаштыра.

Мәктәптә Уралның иң якын дусларыннан берсе соңрак бөтен дөньяга танылган академик, атом-төш физикасы белгече Роальд Сәгъдиев була. Бу ике галимнең дуслыклары бүген дә дәвам итә.

Мәктәпне тәмамлаганнан соң Урал Закиров хәрби комиссариатка килә, аны Ригадагы инженер-авиация училищесына укырга җибәрәләр. Анда ул хәрби самолетларны төзүче һәм аларга хезмәт күрсәтүче инженер һөнәре алып чыга.

Канатлы чор

Хәрби-диңгез флотының авиация бүлегендә эшли башлагач, Урал Нуриевич Ту-16 реактив самолеты белән һавага күтәрелгән пилотсыз канатлы ракеталарга хезмәт күрсәтә. Сүз уңаеннан, мондый самолетлар ул вакытта Казанда җитештерелә. Оборона министры боерыгы белән яшь офицерны әле яңа гына оешкан ракета гаскәрләренә юллыйлар. Шулай итеп аның тормышында яңа – ракета этабы башлана: ул НИИ – 4 дип аталган реактив хәрәкәт институтына килеп эләгә. Хәзер бу уку йорты урнашкан шәһәр Королев исемен йөртә.

1960 елда төрле сәбәпләр белән Совет Армиясендә хезмәт итүчеләрнең санын 1 миллион 200 мең кешегә кыскарталар. Бу офицерларга да кагыла. Ни кызганыч, Урал Закиров та шушы исемлеккә эләгә. Әмма эшләгән гамәлләре дә, һөнәре-тырышлыгы да югалып калырга ирек бирми. Аны Советлар Союзында иң яшерен дип саналган, Сергей Королев үзе оештырган ОКБ-1 тәҗрибә-конструкторлык бюросына чакыралар.

Монда ул чын мәгънәсендә космос дөньясында яши. Беренче космонавт Юрий Гагарин белән әле ул галәмгә очканчы ук таныша. 1961 елның март аенда конструкторларның эш бүлмәсенә бер төркем офицер килеп керә. Җитәкченең килгәнен көткәндә, берәү Уралның өстәленә сөялә. Ул нәкъ менә Юрий Гагарин булып чыга. Алар, тынлыкны бозып, дустанә гәпләшеп тә алалар. Соңрак Урал абый беренче космонавт белән бергә эшли.

Гагарин галәмгә очканнан соң, конструкторлык бюросында: «Ни өчен әле космоска очучылар гына очарга тиеш?» – дигән сүзләр йөри башлый. Отрядка керү өчен инженерлар да гариза яза башлый. Алар арасында Урал Закиров та була. Әмма милләттәшебез медицина тикшеренүен үтә алмый, табиблар күз күрүен начар дип табалар. Галәмгә күтәрелә алмауны фаҗига итеп кабул итми ул: башы-аягы белән фән дөньясына чума. 1963 елда СССР Фәннәр академиясе аспирантурасына укырга керә.

Ай тирәсендәге шау-шу

Айга кем беренче булып оча? СССР белән АКШ арасында көрәш барган еллар була бу. Королевның конструкторлык бюросында инде шактый зур эшләр эшләнгән.

> **1968 елның 15 сентябрендә Байконурда ай тирәли очыш ясар өчен җитештерелгән «Протон» пилотсыз космик корабленә старт бирелә. Аппарат хәвеф-хәтәрсез генә җиргә әйләнеп кайта. Эчендәге сәяхәтче ике ташбакага да бернинди зыян килми. Шуннан соң пилотсыз космик корабльләргә тагын берничә тапкыр старт бирелә әле.**

Барысы да уңышлы була. Әмма америкалылар өлгеррәк булып чыга: 1968 елның 21 декабрендә «Аполлон-8» корабле ай тирәли ун тапкыр әйләнә, ярты елдан астронавтлар да айга аяк басалар. Шулай итеп, СССР өчен бу гамәлнең сәяси яктан әһәмияте югала. Әмма Ай программасы эшләүдән туктамый. «Н-1» дип аталган бик зур йөк ташучы ракета әзерләнә. Бик күләмле булганлыктан, ул тарихка «Патша-ракета» буларак кереп кала. Әмма эш барышында проектның җитәкчесе Сергей Королев үлеп китә. Ун елдан соң үткәрелгән сынаулар вакытында ракета, старт алгач та, 49 нчы секундта җимерелә башлый һәм егерме километр ераклыкта җиргә килеп төшә. Бу вакытта Урал Закиров Королев шәһәрендәге бюрода баш конструктор телефонында кизү тора. Аңа тиз арада бу фаҗигале хәл турындагы хәбәрне җиткерәләр...

– Бәлки шушы күңелсез вакыйгаларның да тәэсире булгандыр, – ди Урал абый, истәлекләргә бирелеп. – Шуннан соң СССР Фәннәр академиясенең фәнни-гамәли математика институтына күчтем. Илебезнең космик һәм атом программаларын җитәкләгән Мстислав Келдыш белән кулга-кул тотынышып эшли башладык. Тик мине үсмер елларым үткән Казан гел үзенә тартты. Кайтасым, шунда төпләнеп каласым килде. Шөкер, хыялымны тормышка ашыра алдым. Кайткач, Казан авиация институтында, СССР Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәгенең физика-техник һәм машина төзелеше институтларында эшләдем. Докторлык диссертациясен якладым. Миңа кайчак: «Балачак хыялын тормышка ашырып, зәңгәр күкне иңли алмагансың икән», – диләр. Бер яктан караганда, шулай тоеладыр ул. Әмма тормышым үкенерлек булмады: илебезнең авиация һәм космос өлкәсенә керткән өлешем белән горурланып яшим.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Авыл җаны

ШӘҺӘР БИШЕГЕ

Нурулла абый белән беренче тапкыр Аксубай районында төбәк тарихчылары конференциясендә очрашкан идек. Шуннан бирле юллар тормышта да, интернет челтәрләрендә дә гел кисешеп тора.

Тарихка кагылышлы дистәләгән китап авторы, тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Нурулла Гариф хәзерге көндә гаиләсе белән Яңа Сала авылында яшәп ята. Быел җәй Чаллының әдәбият-сәнгать әһелләре делегациясе Балык Бистәсендә, шул исәптән Нурулла абыйның музеенда да булып, хәйран калып кайткан идек. Бу кадәр бай музейны булдыру үзе үк кешедәге фидакарьлек белән булдыклылык дәрәҗәсе турында сөйли.

Нурулла абыйның утыз ел Казан тирәсендәге бистәдә физика һәм математика укытканнан соң авылына кайтып китүен сөйләве хикәя сюжеты булып күз алдыма килеп баса минем. Көн дә подъезд төбендә олы яшьтәге ике бабай озатып-каршы алып тора аны. Картлык баскан, куллары калтырый... Мин дә шулай утырырмын микән, дип уйлый пенсия яшенә якынлашкан мөгаллим. Бистәдәге бөтен кеше белә аны: башта ата-аналарын, хәзер балаларын укыта. Узган-киткән исәнләшер инде. Кызганып та карарлар микән? Күрше бабайлар шикелле калтырап утырыр микән? Үги әни дә авылны сагына башлады: җирси, күрәсең. Яшь барган саен, туган җирнең тарту көче дә арта гына бара. Бабаларының бабалары яшәгән ике катлы нигез йорт та чакырып тора шикелле. Тәвәккәлләргә кирәк: кайтырга!..

> **Үз кадеребезне үзебез белик әле дип кайтып, дөрес эшли Нурулла абый. Картлык көнендә кешегә эшчән, хәрәкәтчән, тыныч тормыш кирәк, дип саный ул һәм шул рәвешле яшәп тә ята. Ул биредә бигрәк тә үз стихиясендә.**

Нурулла абыйның маңгай күзе дә, күңел күзе дә ачык күрә. «Мин күп йөрим. Себердә, Уралда, Башкортстанда булдым. Күптән түгел Казахстанда булып кайттык. Чагыштырып караганда, безнең халык бай яши: аның керемнәре күп. Бакчасында бәрәңгесен, кишер-суганын үстерә, мал-туар асрый, урманда гөмбәсен, җиләген җыя, безнең халыкның кул эше бар (шабашкамы, башкасымы – нидер эшли), дәүләткә эшләп, хезмәт хакы да ала. Мин йөргән якларда җирләр кысыр: анда күп җирдә таулар, көтүлек-чәчүлек өчен җирләр аз, кешенең хөкүмәт эшеннән башка кереме юк диярлек. Татарстанның территориясе аз булса да, җиренең бай булуы яхшы яшәргә мөмкинлек бирә», – ди ул.

«Тарихчы, язучы кешегә шәһәрдә яшәү кулайрак түгелме?» – дим Нурулла абыйга. «Кешегә үсеш өчен хәрәкәт кирәк. Авылларда йорттан-йортка йөрсәң, әби-бабайлар белән сөйләшсәң, нинди генә тарих юк монда. Безнең җирлектә борынгы шәһәр, авыллар, борынгы зиратлар бар. Шәһәрнең бишеге авыл инде аның». Миңа калса, җиргә кендеге береккән кеше генә болай уйлыйдыр.

Нурулла абый, авылда яшәү яхшырак хәзер, дип саный: «Капка төбенә, теләсәң, ун кешенең машинасын куярга була. Кайсы яктан чыксаң да, бакчаң бар. Урамга чыксаң – таныш йөзләр. Өч-дүрт йорт саен трактор, машина. Хәзер инде савыт-саба юу машиналары да бар авылда. Интернет та авылда тизрәк эшли. Йортларда душы, мунчасы, канализациясе, телефоны. Авыл кешесе гел эштә ул, шуңа кереме дә күп, баерак та яши...» Чынлап та, шундый парадокс түгелме соң? Авыллар бетеп бара – халыкның тормышы яхшыра.

Авыллар кечерәер, әмма бетмәс, ди Нурулла абый. «Авылларны без бөтенләй үк саклап кала алмабыз, бөтенләй үк бетмәс тә. Авылның өч төп байлыгы – чәчүлек җирләре, көтүлек җирләре, урман – бүләбүлә бүленеп беткән инде. Яңа технологияләр заманында эшчеләр дә күп кирәкми хәзер. Шулай да авылның бер унбиш-егерме проценты калып, анда яшьләр техникада эшләп, бай яшәрләр», – дип уйлый ул.

Нурулла абый, авыл кешесенең әби-бабайлардан калган үз менталитеты бар, ди. «Базда бәрәңгебез бар, быел ачка үлмибез. Шәһәр кешесенең суыткычында бер атналык ризыгы бар һәм ул курыкмыйча яши. Ә безнең базда бер-ике еллык ризык бар, зур-зур суыткычлар тора, ләкин барыбер нәрсәдәндер куркып-борчылып яшибез. Авыл кешесе шундый инде ул», – ди. Авыл кешесенең үзе дә аңламыйча нидәндер куркуы – генетик куркудыр ул: күпме эксперимент үткәрелгән аның өстендә. Илдә чыпчык үлмәс, дигәннәр дә җитештергәнен тартып алганнар, авыл үз-үзен туендырыр дигәннәр дә салымын арттырганнар...

vk.com

Нурулла абыйны да бүген иң борчыган әйбер – тел. «Безнең халык бай яши, акыллы, укымышлы; әмма аның элек-электән килгән менталитет сыйфаты – ул ярарга тырышкан. Барысына да ризалашкан, күндәм булган, эндәшмәгән, башын гел аска игән. Шул сыйфат аркасында без күп нәрсәне югалтабыз. Мәктәпне югалта барабыз, мәктәп белән бергә телне югалта барабыз, үз позицияләребезне бирәбез дә бирәбез».

Өметләндергәне – безнең артта төрки дөнья тора, ди ул. «Ул өч йөз миллионнан арта һәм бик нык үсештә. Соңгы елларда алар берләшә башлады, алфавитлар, икътисадый багланышлар... Киләчәктә әле автоматик тәрҗемә булачак. Тел проблемасы булмаячак. Безнең артта әле ике миллиард мөселман тора. Алар да безне бөтенләй югалудан саклап калачак.

Элек, балалар бер тел генә белә, дип борчылып йөри идем. Хәзер инде болай уйлыйм: менә шул бертеллеләр киләчәктә ике, өч тел белүчеләрнең көтүләрен көтәчәк. Хәзер интернет заманы, технологияләр заманы, көрәк-сәнәк заманы түгел. Акыл, креативлык, белем алга чыга. Һәм биредә күптеллелек, алдынгы карашлылык җиңәчәк». Күптеллелекнең көндәшлеккә сәләтлелекне генә түгел, гомер озынлыгын арттыруга, картлык чирләрен кисәтүгә дә тәэсире бар, ди әле белгечләр.

Китап укуга аның мөнәсәбәте үзгә. Аңлы, җитди, горурлык катыш ярату белән. «Әгәр өч йөз сүз белсә, кеше русча да сөйләшә ала, татарча да сөйләшә ала. Халыкның тел байлыгы бик аз, аңарда – кухня, урам теле. Кимендә унике мең сүз белсәң, ул – әдәби тел. Дөньякүләм аралашу чарасы буларак ундүрт тел арасына татар теле юкка гына кермәгән бит, – дип горурланып сөйли ул. – Төрки телләрдән бер татар теле генә анда, гәрчә татарлар үзләре якынча җиде миллион гына булса да. Татарның әдәби теле бик бай! Үзбәкләр утыз алты миллион, аларның теле кермәгән. Төрекләр сиксән миллион, аларның теле дә кермәгән. Казах төрекне аңламаска мөмкин, ә татар төреген дә, казахын да аңлый. Казахстанга баргач, аларның телләре бик ярлы булуын күрдек, алар шул 300–500 сүз белән аралаша. Кызганыч, күп кеше безнең гаҗәеп бай әдәби телебездән мәхрүм кала».

Хыяллар... «Зур хыялым – халкымның дәүләтле, башкалар кебек телле-динле булуы. Зур мөмкинлекләр туып, балалароныкларның киләчәге өметле булсын дигән хыял да бар».

Менә шундый кешеләр белән аралашканнан соң, минем күңелдә горурлык хисе уяна: мин бу кешеләр арасында яшим бит; мин дә – шул булдыклы татар халкының бер вәкилемен...

Лилия ФӘТТАХОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

ГАНИЕВ ИЛШАТ ГАЗЫЙМ УЛЫ
(03.01.1954 – 22.11.2023)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Майский» теплица комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры Ганиев Илшат Газыйм улы 22 ноябрьдә 70 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Илшат Ганиев 1954 елның 3 гыйнварында ТАССР Баулы районы Яңа Шалты авылында туган. Хезмәт эшчәнлеген, 1976 елда Горький исемендәге Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаганнан соң, ТАССР Яшел Үзән районы «Майский» совхозында агроном буларак башлап җибәргән. 1986 елдан КПСС Татарстан өлкә комитетының авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү сәнәгате бүлеге инструкторы вазыйфасында хезмәт куйган.

Илшат Газыйм улы 1989 елда «Майский» совхозы директоры итеп билгеләнде. Зур куәтле, профессиональ коллективлы теплица комбинатын булдыру һәм үстерү аның исеменә тыгыз бәйле. «Майский» Илшат Ганиев җитәкчелегендә Россиядә яшелчәне ябык грунтта җитештерүче иң зур предприятиеләрнең берсенә әйләнде. Ул һөнәри эшчәнлегенең беренче көннәреннән үк, пестицидлардан һәм теплицаларны химик ысул белән чистартудан баш тартып, җитештерүне технологик яктан үстерү бурычын куйган хәлдә үзенең новаторлык сәләтен эшкә җикте. Шуның нәтиҗәсе буларак, Илшат Ганиев инде 1980 нче елларда ук теплица предприятиеләрендә үсемлекләрне биологик саклауга нигез салучыларның берсенә әйләнде.

Яшелчәне тамчылап сугаруны гамәлгә кертү эшчеләрнең хезмәтен җиңеләйтү, шулай ук продукциянең сыйфатын яхшырту һәм уңышын арттыру мөмкинлеге бирде. Әлеге уңышлы тәҗрибә тармактагы башка оешмаларны да шундый ысулдан файдаланугa этәрде.

Аның катнашында камилләштерелгән яшелчәне ясалма яктылыкка нигезләнеп үстерү технологиясе дә илнең бөтен теплица хуҗалыгы өчен үрнәк булды. Моннан тыш комбинатта иң зур биолабораторияләрнең берсе ачылды. Аның эшләнмәләре яшелчә үстерүдә химик ысулдан тулысынча баш тарту мөмкинлеге бирә.

Илшат Ганиев хезмәткәрләрне социаль яклауга, уңайлы яшәү һәм эшләү өчен шартлар тудыруга зур игътибар бирде. Комбинат территориясендә предприятиенең торак комплексы төзелде. Ул биш катлы 6 йорттан, шулай ук уен мәйданчыклары белән спорт комплексыннан, сквердан гыйбарәт.

Илшат Газыйм улы хәйриячелек белән шөгыльләнде, комбинатта эшләп, пенсиягә чыгучыларга даими ярдәм күрсәтеп килде, дәвалануга мохтаҗларга, торак, башка инфраструктура объектларын төзү һәм төзекләндерүгә булышты.

Халыкның проблемаларына битараф кала алмаган кеше буларак, республиканың иҗтимагый-сәяси тормышында актив катнашты. I, II, IV, V, VI чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты итеп сайланды.

Илшат Ганиев җитәкче таланты, кушылган эшкә карата гаять зур җаваплылык хисе, профессионализмы, мәрхәмәтлелеге белән аерылып торды.

Аның күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм казанышлары югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», «Фидакарь хезмәт өчен», «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оештырылуга 100 ел» һәм «Авыл хуҗалыгындагы хезмәтләр өчен» медальләре, «Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре», «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исемнәр, фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе, Татарстан Республикасы Мактау грамотасы һәм башка бүләкләр.

Илшат Газыйм улы Ганиевнең якты истәлеге күңелләребездә мәңге сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ, Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН, Ә.Ә. СӘФӘРОВ, М.Г. ӘХМӘТОВ, М.А. ҖӘББАРОВ, Ә.С. ГОБӘЙДУЛЛИН, М.П. АФАНАСЬЕВ, И.И. ГОЗӘЕРОВ

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе, әнисе **СИНГАТУЛЛОВА Рузалия Гаяз кызы** вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Рәисе Дәүләт беркетмә идарәсенең тәрҗемә секторы мөдире Сингатуллова Алия Әмир кызының авыр кайгысын уртаклаша.

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе, 1990–1992 елларда КПССның Әлки районы комитеты беренче секретаре, 1992–1995 елларда Әлки районы хакимияте башлыгы вазыйфасында эшләгән **САФИН Хәлим Зөфәр улы**ның кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Фестиваль

ЯШЬ ДРАМАТУРГИЯ

XV фестивальдә – 15 театр. Яшь режиссерларны Казанда очраштыра торган «Һөнәр» фестивалендә быел 15 коллектив 16 спектакль тәкъдим итәчәк. Татарстан режиссерларыннан тыш, алты чит төбәктән киләчәк яшьләр дә үз спектакльләрен тәкъдим итәр дип көтелә. Быел бу чара режиссерларның төрлелеге белән истә калырга охшаган.

Ник дигәндә, узган еллардагы фестивальләрдә бер үк режиссерлар берничә спектаклен тәкъдим итә иде. Быелгы афишада башкорт режиссеры Илсур Казакбаевның гына ике спектакле күренә, алдагы елларда актив катнаша торган Илгиз Зәйниев һәм Айдар Җаббаров куйган спектакльләр программада бөтенләй юк. Казакбаевның исә Башкортстанда түгел, Тинчурин һәм Минзәлә театрларында куйган спектакльләре катнашачак.

Шулай итеп, 1–7 декабрь көннәрендә Казанның 5 театрында (Кариев театры, Камал театры, Тинчурин театры, Казан яшь тамашачы театры, «Әкият» курчак театры), «Тимерьюлчылар мәдәният сарае»нда һәм Буада 16 спектакль куелачак. Татарстанга Ачинск (Красноярск крае), Барнаул (Алтай крае), Сарапул (Удмуртия Республикасы), Губаха (Пермь крае), Туймазы (Башкортстан Республикасы), Чабаксар (Чувашия Республикасы) театр коллективларының килүе көтелә.

– Быелгы фестиваль Укытучылар һәм остазлар елы кысасында уза, шуңа да остазларның яшьләр белән ни рәвешле эшләвен күрсәтергә теләдек, – дип сөйләде фестивальне оештыручы Кариев театры җитәкчесе Луиза Шарова.

Бу җәһәттән Ренат Әюповның «Ал җилкәннәр» (Кариев театры) һәм Фәрит Бикчәнтәев җитәкчелегендә Рамил Гәрәев куйган «Игезәк» (Камал театры) спектакльләре күрсәтеләчәк.

Моннан тыш, Татарстан театрлары арасыннан Кариев театры – «Әлифба: хәрефләр дөньясында» (реж. – Лилия Әхмәтҗанова), Тинчурин театры – «Ашина» (реж. – Илсур Казакбаев), Әлмәт театры – «Дөм» (реж. – Лиза Бондарь), Әтнә театры – «Наташаның хыялы» (реж. – Ичэнь Лю), «Әкият» курчак театры – «Репка – Ряба – Колобок» (реж. – Дилүс Хуҗиәхмәтов), Минзәлә театры – «Шулай булды шул» (реж. – Илсур Казакбаев), Буа театры «А зори здесь тихие» (реж. – Владимир Васильев) спектакльләрен тәкъдим итәчәк.

– Бер генә спектакльне дә аерасым килми, барысы да фестивальдә күрсәтелергә лаеклылар, һәр режиссер үзенчә кызыклы. Программада күбрәк яшьләргә юнәлтелгән спектакльләр урын алды. Монда мәктәп программасына кертелгән классик әдәбият та, заманча драматургия дә бар. Миңа калса, күрсәтеләчәк спектакльләр җәмәгатьчелекне битараф калдырмас, бәлки, ниндидер бәхәс уятыр. Һәм бу бик яхшы нәтиҗә булачак, – диде фестивальнең кураторы, программа директоры Нияз Игъламов.

Фестивальгә багышланган матбугат очрашуында Пермь краеннан килгән яшь режиссер Дмитрий Огородников та катнашты. «Һөнәр»дә аның «Доминанта» камера драма театрында куелган «Тихий свет» спектакле катнаша.

– Мин дә, театр коллективы да әлеге чарада катнашу мөмкинлегенә бик сөендек. Фестиваль бит ул – театрның төрле, шул исәптән шактый катлаулы шартларда эшли алу-алмавын сыный торган чара. Алар шуның белән дә кадерле, – диде ул, киләчәктә Татарстан театрларының берәрсе белән дә эшләп карау теләген яшермичә.

Елдагыча, фестиваль кысасында белем бирү программасы да каралган. Быел Татар китабы йортында төрле темаларга багышланган театраль лекцияләр узачак. Фестивальнең экспертларына килгәндә, Нияз Игъламовтан кала Татарстаннан башка тәнкыйтьчеләр, театр белгечләре юк. Спектакльләрне чакырылган тәнкыйтьчеләр – Юлия Клейман, Марина Шимадина, Жанна Зарецкая бәяләячәк.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Сан

- Фестиваль **2009 ел**дан бирле оештырыла. Аны, Фәрит Бикчәнтәев укыткан режиссерлар курсының (Эмиль Талипов, Лилия Әхмәтова, Дамир Сәмирханов) диплом эшләре смотры буларак, Камал театры гамәлгә куя.
- **10 ел**дан соң оештыру эшләре Кариев театрына тапшырыла.
- Фестиваль **7 көн** дәвам итә.
- Быелгы фестивальдә яшь чикләве **3+** булган спектакльләр дә, **18+** булган спектакльләр дә катнаша.
- **2017 ел**да IX фестиваль кысасында режиссер Регина Саттарованың «Агачлар үскән вакыт» спектаклен Иске Аракчино бистәсе янындагы урманда күрсәткәннәр.

ИЛЬЯС МИНҺАҖЕВ:
«БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНЕ ТАРКАЛА ДИП УЙЛАУЧЫЛАР БУЛДЫ»

Җәһәт әңгәмә

Продюсердан китү авырмы? Арзанлы пиар белән сыйфатлы пиарның аермасы нәрсәдә? Бүген популяр булган җырларга нәрсә җитми? Бу һәм башка сорауларны «MINGAZOV» беренче татар кавер-төркеменең солисты һәм җитәкчесе Ильяс МИНҺАҖЕВка бирдек. Авторлык хокуклары, җырларны бозу һәм якын кешеңне кичерү турында сөйләштек.

:: Күптән түгел төркемнең продюсерсыз эшли башлавын игълан иттегез. Моның сәбәбе нидә?

– Кешене ямьсез итеп күрсәтәсем, аңа пычрак атасым килми. Әмма шунысы факт: продюсердан (Роман Тушев турында сүз бара. – **Авт.**) бөтен командабыз белән киттек. Сәбәпнең кемдә икәне аңлашыладыр инде. Бу адымга барганчы, бик күп тапкырлар сөйләшеп карадык – безне ишетүче булмады. Бер еллап бара инде бу бәхәс. Яшерен-батырын түгел: араларны өзүдә финанс мәсьәләсе дә, аның безгә карата мөнәсәбәте дә роль уйнады. Без бит контрактсыз эшләдек. Ягъни теләсә кемнең теләсә кайсы вакытта төркемнән китәргә хакы бар иде. Ләкин төркемнең социаль челтәрләреннән алып, бергә эшләгән елларда тегелгән костюмнарына кадәр файдалану хокукын продюсер белән килешү нигезендә сатып алырга туры килде.

:: Зур суммагамы?

– Әйе. Ул күпкә зуррак иде. Булды инде анда хәлләр… Әйтәм бит, барысын да сөйлисем килми.

> 9 яшьлек чагымда әти белән әни аерылышты. Шул чакта әти: «18 яшең тулганчы, мин сиңа алимент түлим, соңыннан син миңа түләячәксең», – диде. Әти исән-сау, мин инде аны кичердем. Романнан да төрле сүзләр ишеттем, әмма аңа да үпкәм юк. Мин андый кеше түгел.

:: Димәк, хәзер төркемне син җитәклисең?

– Әйе. Продюсерның барлык вазыйфалары да миңа күчте. Әмма үземне продюсер дип атарга теләмим. Бу исем нәрсә бирә инде? Әлегә үз өстемә алган җаваплылык турында гына уйлыйм. Ярый әле янымда ярдәм итәрдәй кешеләрем бар…

:: Татар эстрадасында продюсер белән «аерылышу»ны үз файдасына боручылар, моннан пиар-кампания ясаучылар булмады түгел. Ә сез бу форсаттан файдаланмадыгыз.

– Безгә андый юл белән танылу кирәкми. Барысын да ничек бар, шулай сөйләсәң, телдән төшмәс тә идек, бәлки. Артист өчен пиар – кирәк нәрсә. Ләкин аның арзаны бар, уйланып эшләнгәне бар.

> Кызганыч, татар эстрадасында арзанлы пиар күбрәк. Бик җитди проблема бу. Андый пиарда барыбер кем дә булса ямьсез итеп күрсәтелә, кемдер гаепле кала. Сыйфатлы, нигезле, нәтиҗәле пиар-кампанияләр күбрәк булсын иде. Бүгенге заманда ансыз булмый.

:: Төркемнең продюсердан китүе турында белдергәч, күп тә үтми, концертыгыз булачагын игълан иттегез. Югыйсә син сөйләгән вакыйгалардан соң хәл алырга вакыт кирәк булгандыр. Февральдә булачак концертыгыз – «Без үзебез дә булдырабыз», – диюегезме?

– Күпмедер дәрәҗәдә. «Пирамида»да концерт кую – күптәнге хыялым. Продюсер белән эшләгәндә, бар нәрсә дә син теләгәнчә булмый бит. Шуңа, озакка сузмыйча, тәвәккәлләргә булдык. Безнең төркемне таркала дип уйлаучылар булды. Бу концерт моның киресен раслар, үсешебезнең киләсе баскычы булыр дип өметләнәм. Безнең максат, миссия – татар җырларын үстерү, ретро җырларны, халык җырларын яшьләр тыңларлык итеп башкару. Концертыбызның форматы да яшьләр өчен аеруча кызыклы булыр дип уйлыйм.

:: Соңгы арада авторлык хокуклары турында күп сөйләшәбез. Сез башка артистларның җырларын башкарасыз, репертуарыгыз танылган җырлардан тупланган. Хокукый яктан бу мәсьәләне ничек көйлисез? Теге яисә бу җырны башкарыр өчен рөхсәт аласызмы?

– Кавер-төркем булгач, андый рөхсәт алу кирәкми. «Кавер» – теге яисә бу артистның җырын яңартып җырлау дигән сүз. Әмма моны аңламаучылар да бар. Бер җырны, сатып алу түгел, башкару хокукы өчен генә дә 2 млн сум акча сораучы булды.

:: Җырларны бозып җырлыйсыз, диючеләр бармы?

– Социаль челтәрләр буенча карасаң, фикер калдыручыларның нибары 1 процентыдыр. Аллага шөкер, иҗатыбызны яратучылар күбрәк.

:: Сезнең репертуарда бүген популяр булган җырлар бик күп түгел. Сәбәбе нәрсәдә?

– Күңелгә ятмый, диимме соң… Мәгънәле җырлар башкарасы килә. Мин бүгенге эстраданы аңлап җиткермим. Блогерлар да җырлый башлады бит… Җырның сүзләренә, мәгънәсенә игътибар итүче аз. Ә бит син җырың белән халыкка ниндидер фикер җиткерергә, анда ниндидер хис-кичереш уятырга тиеш. Җырны вокаль яктан дөрес башкару һәм үтемле итеп җырлау – бер үк нәрсә түгел. Ул яктан тәҗрибә бик зур роль уйный.

:: Ничек уйлыйсың, таланты булып та, таныла алмаган яшь җырчыларга нәрсә комачаулый?

– Хәзер кайда да акча кирәк. Кемгәдер шул комачауларга мөмкин. Ә кайберәүләр, эстрадага килеп кергәндә үк, акча эшләүне максат итә. Бу – шулай ук дөрес түгел. Максат башка булырга тиеш. Аннан соң, кемнәрдер үзләренә ышанып бетми. Бәлки, яннарында: «Син булдыра аласың!» – дип торучылар юктыр.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

МИН ЯШИМЕН СЕЗНЕҢ АРАГЫЗДА
ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ РОБЕРТ МИҢНУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА – 75 ЕЛ

tatar-inform.ru

Искә алу

Шигырьләре һәм җырлары белән барлык татар баласына да яшьтән үк таныш халык шагыйре Роберт Миңнуллинның тууына быел 75 ел булды. Бу уңайдан әле күптән түгел генә Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә аны искә алу кичәсе узды.

Тормышны, кешеләрне, туган җирен, шигъриятне яраткан шагыйрьнең кичәсе дә тәэсирле, уйга сала торган, моңлы булды. Милләтнең сөекле шагыйре турында истәлекләрне барладык.

– Үзе исән булса, 75 яшьлек юбилеен бик матур итеп уздырыр иде. Чараларны, бәйрәмнәрне колачлы, матур итеп үткәрергә бик ярата иде ул. 40 яшеннән башлап шулай итә иде. Үзе өчен түгел, бигрәк тә якыннары, туганнары өчен, якташлары өчен бәйрәм ясыйсы килде, – дип искә алды тормыш иптәшен филармониядә узган чарада Клара Миңнуллина. – Без сагынган кебек, сез дә Робертны, аның җырларын, шигырьләрен сагынгансыздыр, тавышын ишетәсегез килгәндер. Аңа шундый игътибарыгыз өчен бик зур рәхмәт. Әле дә истә: туган ягы – бәләкәй генә Шәммәт авылында Башкортстан, Татарстанның олпат язучыларын җыеп, аларны очраштыра иде. Шундый рухланып кайтып китәләр иде алар! Робертның максаты да шул: язучыларны берләштерү, аралаштыру, элемтәләрне ныгыту. Бик күп чаралар узды, бәйгеләр оештырылды, Республика балалар китапханәсенә Робертның исеме бирелде. Алар бик зур эш башкаралар. Бигрәк тә быел, юбилей елында бик күп көч куйдылар. Роберт Миңнуллин исемендәге әдәби бәйге узды. Быел бик күп эчтәлекле, тирән мәгънәле эшләр килде. Татар теленә омтылу, телебезгә якынаю шуннан башлана да инде. Барыгызга да Робертны зурлап, хөрмәт итеп килгәнегез өчен рәхмәт. Роберт әйтмешли, бәхетле булыгыз! Ул һәр чыгышын шулай дип бетерә иде.

«Халыкның кадерле шагыйре». Татарстанның халык язучысы, Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла 40 елдан артык белгән иҗатташы турында әнә шулай диде.

– Әйбәт кеше иде. Татар милләтенең язмышы өчен борчылды. Форсат чыкса, югары трибуналардан да бу хакта сөйләгәне булды, шул темага шигырьләр дә язды. Әлбәттә, бу сүзләрнең иң төп аһ-зары – киләсе буыннарның ана телен югалтуы, санга сукмавы. Сәбәбен ул, билгеле, белгәндер. Шигырьләрендә шуңа охшаш ым-ишарәләр бар. Әмма төп сәбәпне әйтә алмады. Беребез дә әйтә алмыйбыз. Халыкның кадерле шагыйре, һичшиксез. Тиздән татарча укый-яза белгән һәркем кадерле булачак. Ә табигый яшәешен саклый алган халыкларда, дәүләтләрдә бу – гадәти, шулай булырга тиешле хәл. Ләкин халык күңелен яулый алырлык сәләткә ия шагыйрь булу һәр илдә дә, һәр җирдә дә – феноменаль күренеш. Һәм ул торган саен сирәгәя бара, – дип сөйләде Ркаил Зәйдулла.

Балалар язучысы, шагыйрә Йолдыз Шәрәпова да остазы Роберт Миңнуллин турында истәлекләре белән бүлеште:

– Ул – минем остазым. Бу сүзнең бөтен мәгънәсендә дә. Беренче мөхәррирем, мине эшкә алган кеше. Язучылар берлегенә керү өчен дә фатиха биргән кеше. Мин һәрбер шигыремне, Роберт абый риза булырмы икән, фатихасына тугры каламмы икән, дип язам. Елмаеп кына тора торган, бик җайлы кеше иде. Аның белән эшләргә рәхәт иде, – дип сөйләде шагыйрә. – Мин беренче эшкә килгәндә, әле үзе дә ике атна гына эшли иде. 1986 елны ишекне ачып: «Яшь ленинчы»да эшләү – минем балачак хыялым, сездә урын юкмы?» – дип килеп кердем мин аның янына. Миңа ышаныч күрсәтте, беренче язган язмамны ошатты һәм эшкә дә алды. Аның фатихасы белән мин анда 29 ел эшләдем. Гадел, гади. Юкка гына безнең иҗатта да аңа охшарга тырышу булмагандыр инде. Мин үземне аның шәкерте дип саныйм. Җае чыккан саен әйтәм бу хакта. Рухына дога кылам. Милләт өчен бик күп эшләгән кеше, билгеле. Мине Йолдыз ясарга аның ярдәме шактый тиде. Роберт абыйның вафатыннан соң Яңа Чишмә районы Акъяр авылына искә алу кичәсенә чакырганнар иде. Ерак бит, килеп җитә аласызмы дигәч, мин әйтәм: «Роберт абый хакына Кытайга булса да барам». Чынлап та шулай. Тормышында зур роль уйнаган, терәк булып торган шәхесләр була. Менә Роберт абый шундый кеше иде.

Роберт Миңнуллин исемендәге әдәби бәйгенең «Балалар һәм үсмерләр өчен иң яхшы драма әсәрләре» номинациясендә 1 нче урын алган язучы Айгөл Әхмәтгалиеваның анда катнашуының үз сәбәбе бар:

– Роберт абый – гадилеге белән гали була белгән шәхес. Һәркемгә таныш хисләрне шигырь юлларына салып, өр-яңа, бәгырьне чеметеп алырдай хис тудыра алган шагыйрь. Иҗатыма карата гел игътибарлы булды, якташ дип кабул итә иде бит ул без актанышлыларны. Тугызынчы класста укыганда, «Безнең мәктәпкә бер шагыйрьнең дә килгәне юк», – дип, район газетасына мәкалә язган идем, беркадәр вакыттан соң Роберт Миңнуллинны алып килделәр. Шул көннән башланган үзара ихтирамыбыз әле бүгенгәчә дәвам итә. Бүгенгәчә дим: конкурста катнашуымның иң беренче сәбәбе дә – Роберт абый рухы алдында җаваплылык тою.

«Балачагыбызның бер өлеше». Монысы – шагыйрь Рифат Сәлахның Роберт Миңнуллинга атап әйтелгән сүзләре.

– Роберт абый бик киң күңелле шәхес иде. Иҗаты белән дә соңгы көннәренә кадәр халкыбызга хезмәт итте. Һәр татар кешесе күңелендә йөрткән сүзләрне әйтте. Лирикасында ул саф, эчкерсез, ә балалар әдәбиятында һәрвакыт шаян иде. Дөресен генә әйткәндә, ул балачагыбызның бер өлеше булды. Ул якты дөньядан киткәч, балачак иленә юллар ябылды шикелле. Роберт Миңнуллин халыкныкы иде һәм халкыбыз күңелендә мәңге яшәр, – дип сөйләде ул.

Ләйсән САФИНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 88 (I өлеш); 2023, № 54 (I өлеш), № 80 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктында «113 437 813,7» санын «119 866 313,7» санына алмаштырырга, «нуль күрсәткече белән» сүзләрен «6 428 500,0 мең сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең 1 пунктында «97 325 954,5» санын «103 754 454,5» санына алмаштырырга, «нуль күрсәткече белән» сүзләрен «6 428 500,0 мең сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлешнең 1 пунктында «89 432 633,5» санын «95 861 133,5» санына алмаштырырга, «нуль күрсәткече белән» сүзләрен «6 428 500,0 мең сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

г) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Ихтимал булган гарантия очраклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен түбәндәгеләр исәбеннән үтәү өчен каралган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары исәбеннән – 2023 елга 6 103 099,2 мең сум, 2024 елга 5 811 892,3 мең сум һәм 2025 елга 5 534 768,1 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары исәбеннән – 2023 елга 0,0 мең сум, 2024 елга 161 250,0 мең сум һәм 2025 елга 193 500,0 мең сум күләмендә.»;

д) түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:

«7. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре программасын әлеге Законга 2^1 нче кушымта нигезендә расларга.»;

2) түбәндәге эчтәлекле 2^1 нче кушымта өстәргә:

«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына
Татарстан Республикасы бюджеты турында»
Татарстан Республикасы Законына
2^1 нче кушымта

2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына
Россия Федерациясе валютасында
Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре программасы

1 нче таблица

2023 елда Россия Федерациясе валютасында бирелә торган
Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре исемлеге

№ п/п	Гарантияләү юнәлешләре (максатлары)	Принципалларның категорияләре һәм (яисә) исемнәре	Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләренең гомуми күләме (мең сум)	Гарантның принципалларга карата регресс таләбе хокукы булу	Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен бирүнең һәм үтәүнең башка шартлары
	2	3	4	5	6
	«Проект финанслауның махсуслаштырылган җәмгыятьләре облигацияләрен кулланып, проектларны финанслау кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясендә региональ үсеш буенча Хөкүмәт комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 31 декабрендәге 2459 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары кысаларында проектларны гамәлгә ашыру	«Татдортранс-инвест» АҖ	6 428 500,0	Юк	1. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе принципалның шартнамә буенча заем (төп бурыч һәм процентлар) бурычын каплау буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә. 2. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе принципалның штрафлар, комиссияләр, заемны соңарып каплаган өчен һәм процентларны соңарып түләгән өчен пенялар, башка түләүләр башкару буенча йөкләмәләрен үтәүне, шулай ук шартнамә буенча башка йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итми. 3. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе принципалның шартнамә буенча йөкләмәләрен вакытыннан алда үтәүне тәэмин итми, шул исәптән принципалга аларны вакытыннан алда үтәү турында таләп куелган йә принципалның йөкләмәләрен үтәү срогы җиткән дип санала торган вакыйгалар (хәлләр) килеп чыккан очракта. 4. Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе буенча субсидиар җаваплылыкка ия.

2 нче таблица

2024 һәм 2025 елларда
Россия Федерациясе валютасында бирелә торган
Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре исемлеге

№ п/п	Гарантияләү юнәлешләре (максатлары)	Принципалларның категорияләре һәм (яисә) исемнәре	Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләренең гомуми күләме (мең сум)		Гарантның принципалларга карата регресс таләбе хокукы булу	Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен бирүнең һәм үтәүнең башка шартлары
			2024 ел	2025 ел		
	2	3	4	5	6	7
	-	-	-	-	-	- »;

3) 6 нчы кушымтаның 2 нче таблицасында:

«Башка бюджет ассигнованиеләре 11 1 1 99 0 00 0741 0 00 6 938 200,0 7 215 700,0»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

«шул исәптән: ихтимал булган гарантия очраклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен үтәүгә җибәрелә торган акчалар 11 1 1 99 0 00 0741 0 00 161 250,0 193 500,0»;

4) 7 нче кушымтаның 2 нче таблицасында:

«Башка бюджет ассигнованиеләре 1 1 99 0 00 0741 0 00 6 938 200,0 7 215 700,0»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

«шул исәптән: ихтимал булган гарантия очраклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен үтәүгә җибәрелә торган акчалар 1 1 99 0 00 0741 0 00 161 250,0 193 500,0»;

5) 8 нче кушымтаның 2 нче таблицасында:

«Резерв фондлар 99 0 00 0741 0 00 1 1 6 938 200,0 7 215 700,0»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

«шул исәптән: ихтимал булган гарантия очраклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен үтәүгә җибәрелә торган акчалар 99 0 00 0741 0 00 1 1 161 250,0 193 500,0».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 24 ноябрь
№ 115-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык тугызынчы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:
Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кырык тугызынчы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
2. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 503-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
3. «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 485-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
4. «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 486-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
5. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 507-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 506-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 501-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 500-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 502-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 505-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
11. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8^1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 504-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
12. «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 488-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
13. «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» 479-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
14. «Россия Федерациясе дәүләт теле турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 468229-8 номерлы федераль закон проекты турында (гавами киңлектә Россия Федерациясе дәүләт теле буларак рус телен куллануны тәэмин итү хакында).
15. «Эскроу счетлардан файдаланып төзелеш подряды шартнамәләре буенча торак йортлар төзү турында» 471420-8 номерлы федераль закон проекты хакында (шәхси йортлар төзүдә һөнәри подрядчы оешмаларны проекттагы финанслау турында).
16. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына «Эскроу счетлардан файдаланып төзелеш подряды шартнамәләре буенча торак йортлар төзү турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә үзгәрешләр кертү хакында» 471417-8 номерлы федераль закон проекты турында (шәхси йортлар төзүдә подрядчы оешмаларны проекттагы финанслауны кертүгә бәйле рәвештә законнарны камилләштерү хакында).
17. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 149 статьясына үзгәреш кертү турында» 471415-8 номерлы федераль закон проекты хакында (подрядчы эшләрен өстәмә бәягә салым салудан азат итү турында).
18. «Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән куркынычсыз эш итү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 471418-8 номерлы федераль закон проекты турында.
19. «Куркыныч җитештерү объектларының сәнәгать иминлеге турында» Федераль законның 13 һәм 14 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 471414-8 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт хезмәтләре күрсәтү срокларын оптимальләштерү өлешендә).
20. «Россия Федерациясендә эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 468216-8 номерлы федераль закон проекты турында (вәкаләтләрне киңәйтү өлешендә).
21. Хөкүмәт сәгате: «Россия Федерациясе Пенсия иминияте һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге эшчәнлеге турында».
22. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 23 ноябре
№ 2232-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп вәкаләтләре чоры чикләнмәгән вакытка түбәндәгене сайларга:

Татарстан Республикасы Азнакай суд районы буенча:

3 нче суд участогына – Калиниченко Маргарита Михайловнаны.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 23 ноябре
№ 2233-VI ДС

КОТЛЫЙБЫЗ!

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Азнакай муниципаль районы буенча Азнакай шәһәреннән биш бала анасы **Нарзуллаева** Фирүзә Фәннур кызы, Әлмәт муниципаль районы буенча Әлмәт шәһәреннән сигез бала анасы (аларның җидесе өч яшькә җиткән) **Сибгатуллина** Айгөл Фидарис кызы, Чүпрәле муниципаль районы буенча Иске Чүпрәле авылыннан биш бала анасы **Яфизова** Рәзинә Нәсих кызы **Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Нагаев** Миргалим Әхмәт улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

ЯҢА ЗАКОННАРНЫ АҢЛАТАБЫЗ

Ноябрь аенда республиканың яңа законнары үз көченә керде. Үзгәрешләр теркәлмәгән гаражларның җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләрен башкаруга, митинглар һәм демонстрацияләр үткәрү, хуҗасыз хайваннар белән эш итү чараларын оештыру тәртибенә кагыла. Моннан тыш, закон нигезендә, күпбалалы хәрбиләр гаиләләре өчен җир кишәрлекләрен бирү тәртибе гадиләштерелә. Яңа законнарга тәфсилләбрәк тукталып үтәбез.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Гараж амнистиясе дәвам итә

«Гражданнарның гаражларга һәм гаражларның җир кишәрлекләренә хокук алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 113 нче Закон үз көченә керде.

Закон нигезендә муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына теркәлмәгән гаражларга һәм гаражларның җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләрен башкару хокукы бирелә.

Шул ук вакытта җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының әлеге эшләрне башкаруга хокукы турында нигезләмә төшереп калдырылган.

Митинглар һәм демонстрацияләр үткәрү тәртибе

«Татарстан Республикасында җыеннар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыруга гражданнарның хокукларын тормышка ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 107 нче Закон гамәлгә керде.

Законда митинглар һәм демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздырылганда транспорттан файдалану тәртибе җайга салынган. Анда, аерым алганда, бер колонна составында «ВЕ» һәм «СЕ» категорияләрендәге транспортның максималь саны билгеләнгән. Мондый машиналар 15тән артмаска тиеш.

«ВЕ» категориясе – тагылма арбалы (авырлыгы 750 килограммнан артмаска тиеш) «В» категориясендәге автомобильләр. Ә инде «СЕ» категориясе – тагылма арбалы (авырлыгы 750 килограммнан артмаска тиеш) «С» категориясендәге автомобильләр.

Бер транспорт колоннасында транспорт саны артмаска тиеш:
1) «А» категориясе өчен – 35 берәмлектән;
2) «В» категориясе өчен – 30 берәмлек;
3) «С» категориясе өчен – 25 берәмлек;
4) «Д» категориясе өчен – 20 берәмлек;
5) «ВЕ» һәм «СЕ» категорияләре өчен – 15 берәмлектән.

Республика Хөкүмәтенә экология өлкәсендә өстәмә вәкаләтләр бирү

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 112 нче закон үз көченә керде. Документта Министрлар Кабинетына экология өлкәсендә өстәмә вәкаләтләр бирү күздә тотылган.

Хөкүмәткә, аерым алганда, каты коммуналь калдыклар күләмен исәпләү ысулын билгеләү тәртибен раслау, әйләнә-тирә мохиткә тупланма зыян объектларын ачыклау, аларны юкка чыгаруны оештыру вәкаләтләре билгеләнгән.

Хуҗасыз хайваннар белән эш итү чаралары өчен җаваплылык

«Татарстан Республикасында хайваннар белән эш итү өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 108 нче Закон гамәлгә керде. Документ сукбай хайваннар белән эш итү мәсьәләләрен җайга салуны күздә тота.

Анда Министрлар Кабинетына хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеге чараларын оештыру вәкаләте бирелгән.

Күпбалалы хәрбиләр гаиләләренә бушлай җир кишәрлекләре бирү тәртибе гадиләштерелә

«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32.1 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 114 нче Закон гамәлгә керде. Анда күпбалалы хәрбиләр гаиләләре (ата-ананың берсе яки икесе дә хәрби булырга мөмкин) өчен бушлай җир кишәрлекләрен бирү тәртибе гадиләштерелә.

Хәзер өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләргә җир кишәрлеге бирү өчен мәҗбүри шарт булып кимендә соңгы биш ел эчендә Татарстанда яшәү тора.

Кабул ителгән закон исә күп балалы хәрбиләр гаиләләре өчен бу шартны юкка чыгара.

Шулай итеп, җир кишәрлеге бирү турында гариза белән бергә тапшырылырга тиешле документлар исемлегенә, «Хәрби хезмәткәрләрнең статусы турында» 27 май, 1998 ел, № 76-ФЗ Федераль закон нигезендә, хәрби хезмәткәрнең статусын раслаган документ өстәлә.

Бу елның 1 июненә булдырылган мәгълүматларга караганда, Татарстанда җир кишәрлекләрен алуга дәгъва кылучылар исемлегенә 98 хәрби хезмәткәр гаиләсе кертелгән. Шуның 48е әлегә җир белән тәэмин ителмәгән.

Сәламәтлек турында мәгълүматлар карала

«Татарстан Республикасында гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 109 нчы Закон үз көченә керде.

Закон нигезендә, хәзер Министрлар Кабинеты һәр ел саен Дәүләт Советына республикада яшәүчеләрнең сәламәтлеге турында доклад тапшырачак.

Социаль сәясәт комитеты рәисе Светлана ЗАХАРОВА:

Еллык докладны сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органы әзерләп, Министрлар Кабинеты аны парламентка тапшырачак.

Җирле үзидарә органнарына гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү

Киләсе елның 1 гыйнварыннан «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 111 нче закон үз көченә керә.

Закон муниципалитетларда ЗАГС органнары эшчәнлеген камилләштерүгә юнәлдерелгән.

Хәзерге вакытта Татарстанда 2 шәһәр округы (Казан һәм Чаллы шәһәрләре), 43 район, шулай ук кайбер авыл җирлекләре гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшен башкарып килә. Кабул ителәчәк законда башкарма комитетлары теркәү вәкаләтләренә ия булып кына калмыйча, бәлки аны тормышка да ашырып килүче 22 җирлектән торган исемлек билгеләнгән.

Моның сәбәбе – 11 муниципаль районда тиешле вәкаләтләр бирелгән 20 шәһәр һәм авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елдан бирле бер генә теркәү гамәлен дә башкармавы ачыкланган. Нәкъ менә шундый муниципалитетларда җирле үзидарә органнарының гражданлык актларын теркәү вәкаләтләре туктатыла.

Әмма Татарстанда яшәүчеләргә бу үзгәреш кыенлык тудырмаячак. Ник дигәндә, Федераль закон нигезендә, 2021 елның 30 декабреннән теркәүгә вәкаләтле 67 органның теләсә кайсына мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Уйлы күңел уйлана

ЧЕМОДАНЫҢ ТУТЫРЫЛГАН БУЛСЫН

Яз көне үткән авыл җыенында җирлек башлыгы Рәсим Латыйпов: «Ишеткәнсездер дә инде, быел өч балалы гаиләләргә үз авылыбыздан, менә шушы урамга параллель урыннан җир бирәчәкбез», – дигәч, авыл зурая икән, бирсеннәр, төзесеннәр, дип сөендек. Алайса, соңгы ике-өч елда авыл күзгә күренеп картайды, кешеләр саны күпләп кимеде, вафат булучылар моңарчы күрелмәгән дәрәҗәгә җитте. Мәчет карты булып йөрердәй өлкәннәребез калмады да бугай инде. Шундый бабайларыбыз гына да дистәләп китте. Аларга яшьләр, хатын-кызлар да «иярде»: бер көнне икешәрләп тә, бер гаиләдән санаулы көн эчендә икешәрләп тә киттеләр. Ковид та үз эшен эшләде, аннан соңгы елларда да саннар уңай якка үзгәрмәде.

Зиратка бармый тормыйбыз. Безнекеләр зиратның аскы өлешендә генә. Күбрәк үзебезнекеләр янында булам да кайтып китә идем. Күптән түгел туганнар белән бөтен зиратны әйләнергә булдык. Өске якка менгән саен гаҗәпләнүем арта барды: безнең биләмәдән соң бераз баруга зиратта ялан кадәр бушлык иде – буш урыннар калмаган дисәң дә була… Дистә еллап элек кенә зират өске якка зурайтылган, анда да иркенлек иде. Ул урыннар да тулы… Күп дигәндә яңадан бер рәт җирләрлек урын калган. Кабер ташларындагы исемнәрне укыган саен йөрәк кысылып-кысылып куя: әле генә җир җимертеп йөри иде бит… Түзмәде, Балтачта яшәүче апам: «Без белгән авыл монда күчкән икән», – дип куйды. Кызганычка, мондый хәл бездә генә дә түгел.

Уйланмас җирдән уйланырсың. Кешегә гомер шулкадәр санап бирелгән. Беребез дә кайчан үзенең сәгате сугасын белми. Әмма ул вакытка син һәрчак әзер булырга тиеш. Туфан абый әйткәндәй, «чемоданың тутырган булырга тиеш». Шундый кинәт үлемнәр күбәеп киткәч, бер танышым: «Коръән укырга өйрәнмичә дә китеп барам бугай инде», – дип, дини гыйлем алуга керешкән иде. Ә бер авыл имамы авылдаш ир-атларны: «Мәчеткә йөрергә дә өлгерми каласыз бит», – дип вәгазьләгән, диделәр…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Үз илемдә – үз телем

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстандагы төрле милләтләрнең яшәеше, гореф-гадәтләре белән таныштыра, «Бер гаилә мисалында туган телне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзли.

ТАТАР

Теләче

ТӘРБИЯ

Теләче районындагы Шәтке авылында халык «Шәтке бабай чишмәсе»ннән су эчә. Авылга нигез салган кешенең исеме ул. 124 баскычны атлап түбән төшкәч, челтерәп аккан суга, ял итү урыннарына юлыгасың. Янәшәдә генә яшәүче Айрат Якупов бу чишмәне 30 елдан артык карап, яңартып торган. Аның ярдәме белән су хәзер торбалар аша һәр йортка килә. Авылдашлары өчен шушы изге гамәлне башкарган гаиләгә без «Туган телне, гореф-гадәтләрне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзләп килдек. Сәбәбе дә бар: гаиләдә дүрт буын вәкиле яши. Иң өлкән кеше – 82 яшьлек Миңлебикә апа, мондый бердәмлекнең нигезендә тәрбия ята, дип уйлый. Бу җәһәттән без барысының да фикерләрен тыңлап кайттык.

Сәхифәне Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде.
Фото – Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ

Күңелгә ни тия?

Миңлебикә апа Шәткегә Олы Нырсы авылыннан килен булып төшкән. Хәзер кече улы Азат белән төп нигездә яши. Айрат гаиләсендә дә еш кунак.

– Элегрәк тормыш бик авыр иде. Без, сугыш чорында туган балалар, бер дә рәхәт күрмәдек, – дип истәлекләргә бирелде ул. – Әмма рухи яктан бик бай яшәдек. Биш бала үстердек. Өчесе авылда төпләнеп калды. Мактанып әйтүем түгел, балаларымның һәрберсе алтынга тиң. Бик бердәм булып яшиләр. Моның нигезендә дөрес тәрбия ята, дип уйлыйм. Шул җәһәттән бер вакыйганы гына сөйләп үтәм. 1992 елны күршем, трактор белән кереп, йортыбызны җимерде. Балаларым, җыелышып, көн-төн эшләп, бер ай эчендә өй җиткезделәр. Бүгенге көнемнән бик канәгать. Өч киленем белән ялгыш кына да сүзгә килгәнем юк. Әмма күңелгә тигән кайбер нәрсәләр бар инде. Колак салгалап йөрим шулай: саф татар авылында балалар рус телендә сөйләшә башладылар хәзер. Бик аяныч хәл бит бу. Русча белергә кирәк анысы. Хәтерлим әле, кайчандыр үземә дә ярдәме тигән иде. Мин үсмер чакта авылга рус милләтеннән бер ханым агроном булып килде. Шуның белән аралашып йөреп, әз-мәз русча сукаларга өйрәндем. Шул вакытта, русча белә дип, почтага коммутатор итеп эшкә алдылар. Аннан дуңгыз фермасына күчәргә туры килде. 31 ел эшләп, пенсиягә чыктым.

> Хәзер балалар русчага тартылалар, туган телләрен оныта баралар. Шуңа күрә, бик борчылып, оныкларымны тәрбияләүгә үз өлешемне дә кертергә тырышам. Мәктәпкә чыгып киткәндә, бисмилла әйтергә онытмагыз, дим. Догалар өйрәтәм.

Кызык кына хәлләр килеп чыга кайчак. Былтыр тарих китабы рус телендә иде. Быел нишләптер татарчасын биргәннәр. Рус телендәгесе булмаган, ахры. Шулай диделәр. Аптырады инде оныгым. Аңламыйм, ди. 82 яшемдә үзем аңлатып утырам хәзер. Татар әдәбияты белән дә шул ук хәл. Нәрсә дисәгез дә, безнең заманга җитми инде. Әлифба китабыннан башланган белемне арттырып кына бардык бит без. Хәзер ике телне бергә кушып, балаларның башын бутап бетерәләр, ахры.

Мәктәптә рус телендә укытып, кечкенәдән үк авылны ташлап китәргә өндиләр сыман тоела. Хәер, әти-әниләр үзләре үк шулай әйтә инде. Эш юк, диләр. Килешәм, әмма синеке, минеке, күршенеке киткәч, авыл, чыннан да, бушап кала шул инде. Монда төпләнеп калганнар да югалмыйлар анысы. Әмма кыенлыклар бар. Чыгу юлын без генә хәл итә алмыйбыз. Иң беренче чиратта авылны торгызырга кирәк. Шул вакытта тел дә, гореф-гадәтләр дә сакланыр, яшьләр дә китмәс иде.

Тормыш кагыйдәләре

Миңлебикә апаның олы улы Айрат хәләл җефете Дамилә белән, йорт җиткереп, башка чыкканнар. Җир кешеләре. Өченче сыйныфтан берсе фермада ат җигеп эшләгән, икенчесе сыер сауган.

– Авылдан китәсе килмәсә дә, башкаларга кызыгып, укырга кереп карадым әле мин. Исәбем биюче булырга иде, – дип, Айрат та хатирәләргә кереп китте. – Имтиханнарны бирдем. Бер сантиметр ярым буең җитми дип алмадылар. Көенеп түгел, сөенеп кайтып киттем. Күңел түрендә йөрткән хыялым бар иде минем. Ул вакытта машина йөртү бик абруйлы һөнәр, горурлык булып саналды бит. Кыскасы, кулда таныклык булса, син чын егет инде. Усадка барып, берьюлы шофер, токарь, сварщик, слесарь һөнәрләре алып чыктым.

Машина бирсәләр, авылда калам, дип, үземә сүз беркетеп куйдым. Армиягә киткәнче үк эшли башладым. Хезмәт итеп кайткач, автобус бирәбез, диделәр. Тагын укырга киттем. Көн-төн руль артында йөрисең, ардыра да кебек, әмма рәхәтлекне аңлатып бетерә торган түгел. Аннан дөньялар үзгәрде, терлек-туар асрый башладык. Кайберәүләр миңа: «Ничек шулай күп итеп хайван асрарга булдыгыз?» – дип сорау бирә. Тормыш үз кагыйдәләрен кертә инде ул. Әүвәл башкалар кебек бер сыер, берничә сарык, кош-корт тоткан идек. Аннан малайлар кул арасына керә башлады. Алар исәйгән саен, акча да күбрәк кирәк. Сөйләштек-киңәшләштек тә, бергәләп тотындык. Эшләмибез, димәделәр берсе дә.

> Үз тормышымнан чыгып, шуны әйтәм: әгәр балаларны кечкенәдән өйрәтмәсәң, кушып кына эшләтсәң, бернәрсәгә дә ирешеп булмый. Кызыктыра белергә кирәк.

Иренең сүзен җөпләп, Дамилә дә кушылды.

– Ир баланың төп нигездә калуы – борын-борыннан татар халкына хас гореф-гадәт инде ул. Улыбыз Айнур: «Мин авылда калам», – дип, үзе теләк белдерде. Кече-кечедән хайваннарны бик яратты. Гел ат җигеп йөрде. Машинага да утырасы килмәде. Гаилә корды. Күршедә генә тагын бер йортыбыз бар. «Аерым яшисегез килсә, башка чыга аласыз», – дидек. Юк, китәселәре килми. Киленнең эштән кайтканын көтеп утырып булмый. Терлек тә карыйм, ашарга да пешерәм, оныкларны да карашабыз. Хәзер дүрт сыерыбыз, ике танабыз, ике үгезебез, кош-кортларыбыз, 12 гектар җиребез, елның теләсә кайсы вакытында кирәкле техникабыз бар. Аерым торсак, без бу кадәр эшне алып та бара алмас идек. Бөтен көч – бергәлектә.

Айнур белән Гөлназ фермада эшлиләр: йөз сыер савалар. «Иртәнге сәгать өчтә чыгып китәләр. Соң гына кайтып керәләр», – ди әниләре. – Тик хезмәт хаклары бик аз. Мондый акчага бары тик җиргә кендекләре белән береккән кеше генә эшли ала, дип уйлыйм. Тик эшенә күрә әҗере дә булсын иде шул. Югыйсә яшьләрне авылда ничек калдырасың? Ничек кенә әйләндерсәң дә, барысы да шул эш урынына, акчага барып терәлә бит.

Сүз уңаеннан, балаларга дип тәгаенләгән йорт та игелек кылганга бүләк кебек килеп чыккан. Янәшәдә генә әби белән бабай яшәгән, соңрак әби ялгызы калган.

– Бу йортны салырга мин аларга үзем булышкан идем. Туганнары да бар иде авылда, нишләптер килеп йөрмәделәр. Күрше булгач, булыштык, ташламадык инде. Көннәрдән беркөнне ул туганнарын чакыртып алды да: «Мине кем карарга риза, йортым шуңа була», – диде. Берсе дә дәшмәде. Күз йөртеп чыкты да миңа текәлеп калды. «Соң, моңарчы ничек карадык, шулай ярдәм итәрбез, йорт өчен түгел», – дидем. Ул шулай да мал-мөлкәтен безгә яздырды, өч айдан китеп тә барды, – ди сөйли Айрат бу хакта.

Бездән соң ничек булыр?

Якуповларның тагын бер улы Айдар гаиләсе белән Теләчедә яши. Авылны, телне саклау турында фәлсәфә куерып барганда гына кайтып төште алар. Янында хәләле Энҗе һәм өч улы. Айсаф, Айзат, Айтуган – өчесе дә хоккей уйнарга йөриләр. Өлкәнрәкләре мәктәптә укый – капкачылар, кечкенәсе әле балалар бакчасында гына, тимераякта йөрергә өйрәнә, әмма абыйларыннан калышырга исәбе юк.

– Мин бу темага хәзер балалар белән дә сөйләшәм инде. «Бездән соң, сездән соң ни булыр икән?» дигән сорауны еш бирәм, – дип кушылды әңгәмәгә Айдар. – Туган телне югалтасы килми. Улларыбыз Теләчедә татар мәктәбендә укый, атнасына ике тапкыр татар теле белән әдәбият дәресләреннән артыгы юк. Кайбер чаралар гына татарча үтә. Гаепләп әйтүем түгел. Бар җирдә дә шулай, бездә дә шул ук программа буенча укыталар. Әмма югарыдагыларның ишеген кагасы, үзгәртәсе килә. Депутатлар бу хакта нәрсә уйлый икән? Без үзебезчә тырышабыз инде. Өйдә татарча гына сөйләшәбез. Ялгыш әйтсәләр, русча сүз кыстырсалар, төзәтәбез. Әмма бу гына җитми бит. Күзәтүләремнән чыгып, тагын шуны әйтә алам: дин юлына баскан балалар телгә дә, гореф-гадәтләргә дә саграк карый. Әдәплерәк тә, миһербанлырак та була. Безгә бу хакта да онытмаска кирәк.

Нинди генә фикерләр булса да, без Якуповлар гаиләсеннән нигез таркалмас, туган тел онытылмас дигән өмет белән киттек. Моның сәбәпчеләре – төп йортта яшәүче оныклар – Айгизә, Айзилә һәм Айгиз. «Авылда шундый рәхәт. Саф һава, тәмле чишмә суы, тыз-быз машиналар йөрми», – диеште алар. Айгизә 5 нче сыйныфта укый. «Киләчәктә кем буласың килә?» – дип сорагач, ул миңа, язып барыгыз, дип берничә һөнәр санады. «Тик әлегә беркемгә дә әйтмәгез, сер булып калсын», – дип тә өстәде. Шәп һөнәрләр. Кайсын сайласа да, тормышта югалып кала торган түгел. Ә менә Айзилә инде күптән сайлап куйган. «Мәктәпне тәмамлагач, Казанда башлангыч сыйныф укытучысы булырга укыйм да авылга кайтам. Үзем укыган мәктәптә туган телемдә укытасым килә. Балалар саны кимеп, мәктәп кенә ябыла күрмәсен иде. Без бүген дә сыйныфта дүртәү генә. Апаларда иң күбе – 12. Иң азы 1 нче сыйныфта. Быел бер бала гына укырга керде», – диде ул, борчылып. Дүрт яшьлек Айгиз исә апаларыннан да уздырды. «Казанга бармыйм, Шәткедә калам», – диде. Әйтергә кирәк, бу йортта барысы да дүрт яшьлек малайның сүзләренә өметләнә. Инде бүген үк чын хуҗа итеп хис итә ул үзен. Апалары эшләгән эшләрен санап бетерә алмадылар. Сыерларга, тавыкларга ашарга бирә, күкәй җыя, асларын тирестән чистарта. Ишегалдын себерә, кар көри. Җәй көне иртән каз-үрдәкләрне үзе чыгара, карый, кичләрен куып кертә, ашата-эчертә. Өйне җыештыра, гөлләргә су сибә... Дәү әтисе аңа сәнәк, себеркеләрне кисеп, бәләкәйләтеп биргән. Апаларының мәктәптән кайткач, дәрес әзерлисе, дәү әниләренә аш-су тирәсендә булышасы бар, ә аның әле өй тирәсендә хуҗа булып йөрергә вакыты күбрәк.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 13584 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 358

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+